МАТЮШИНО УҢЫШЫ
Иң яхшы авыл мәктәбе булу өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк?
> 3

РОБЕРТ СӘЛӘХИЕВ:
«Авылда хәзер бу тормышка кул селтәгән, бар әйбергә дә битараф әбиләр дә бабайлар...»
> 4



ХАТЛАРДА – ЙӨРӘК ҖЫЛЫСЫ
Укучыларыбыз кадерле истәлекләре белән уртаклаша
> 6



ХА-ХА-ХАНӘ
Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр монда
> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 135–136 (29102–29103) | Сишәмбе | 19 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ТЕЛӘК БЕЛӘН ТОРАК АРАСЫ

Фатир хәлләре

Моннан ары торак сатып алырга теләүчеләргә акчаны тагын да күбрәк җыярга туры киләчәк. Ил Хөкүмәте ташламалы ипотека буенча беренче кертем күләмен 15тән 20 процентка кадәр күтәрде. Бүген яңа торакның 80–90 проценты ташламалы ипотека программалары ярдәмендә сатылуын исәпкә алсаң, халыкның күпчелегенә кагыла торган яңалык бу. Тик кәефегезне төшерергә ашыкмагыз. Бер яктан артса, икенче яктан кимергә дә мөмкин әле. Нәрсә һәм кайчан?

Яңа торак сатып алу турында сөйләшә башлагач та, әй, бүгенге заманда нинди акча турында сөйләшү ул, дип кул селтәргә ашыкмагыз. Росреестрның Татарстандагы идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, быелның гыйнвар – август айларында республикада 38 меңгә якын торак ипотекасы рәсмиләштерелгән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, «түбә»ле булырга теләүчеләр 35 процентка күбрәк. Бигрәк тә август шаккатырган. Җәйнең соңгы аенда Татарстанда фатирларга сорау 51 процентка (!) арткан.

– Соңгысы Үзәк банкның августта төп ставканы 12 процентка кадәр (15 сентябрьдән – 13 процент. – **Ред.**) күтәрүенә бәйле, дип уйлыйм, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Төп ставка артыннан банкларның да процент ставкасын күтәрүе көн кебек ачык. Моңа сумның очсызлануын, инфляцияне дә өстәсәң, җыйган акчага милек сатып алу хәерлерәк, әлбәттә. Ул – үз кыйммәтен югалтмый торган актив. Татарстан яңа торакның бер квадрат метры бәясе буенча ил күләмендә дә беренче унбиш төбәк арасына керә. Республикада бүген әлеге күрсәткеч 130 мең сум чамасы.

Саннардан күренгәнчә, бүген илдә яңа торакның 80–90 проценты ташламалы ипотека программалары ярдәмендә сатыла. Икенчел торак базарында әлеге күрсәткеч иллегә илле чамасы, ди белгечләр. Халык арасында иң зур кызыксыну уятканы – яңа йортлардагы фатирларга 8 процентлы ташламалы ипотекадыр, мөгаен. Билгеле булганча, әлеге ташламалы программа киләсе елның 1 июленә кадәр озайтылды. Гаилә ипотекасының процент ставкасы – 6 процент. Моннан тыш, Ерак Көнчыгыш ипотекасы – 2, IT-тармакта эшләүчеләрнеке – 5, ә банклар аны тагын да киметергә мөмкин, процент тәшкил итә. Ә менә авыл ипотекасына килгәндә, Үзәк банк төп ставканы күтәргәннән соң, 0,1–3 процентлы әлеге программаны вакытлыча туктаттылар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ташламалы ипотека ул – банкларның клиентларга милек сатып алу өчен түбән процент белән заем бирүе, ә базар һәм ташламалы ставкалар арасындагы аерманы дәүләт үзе түли.

Бу атнада ташламалы ипотека буенча беренче кертем күләмен 15тән 20 процентка кадәр күтәрделәр. Ил Хөкүмәте карарыннан аңлашылганча, яңалык моңарчы төзелгән килешүләргә кагылмый. Шулай ук ташламалы ипотека программаларын финанслау өчен кредит оешмаларына субсидия күләмен дә 0,5 процентка киметтеләр. Әлеге яңалыктан соң ипотека торагы базарында килешүләр саны 20 процентка кадәр кимергә мөмкин, дип фаразлаган белгечләр.

Тик торак базарында «кайнаучы»лар моның белән килешергә ашыкмый.

– Фатир сатып алырга җыенган кеше өчен 5 процент әллә ни зур күрсәткеч түгел, – ди башкаладагы милек агентлыкларының берсендә эшләүче риэлтор Дамир Гәрәев. – Мәсәлән, бүген Казанның Киров районындагы яңа йортта бер бүлмәле студия өчен 585 мең сум күләмендә беренче кертем кирәк булса, яңалык үз көченә кергәч, ул 780 мең сумга әвереләчәк. Фатир кадәр фатир сатып алырга җыенган кешегә 200 мең сум аерма алай ук күп түгел, минемчә. Дөрес, акчаны озаграк җыярга туры киләчәк. Торак бәясе арта, ә халыкның керем дәрәҗәсе шул ук. Фатир сайлау эшенә дә җаваплырак карый башлаячаклар дип уйлыйм.

Бер начарның бер яхшысы була, дигән фикер дә әйтте риэлтор.

– Беренче кертем күләме арту яңа торак базарында бәяләр азмы-күпме төшүгә китерергә мөмкин, – ди Дамир Гәрәев. – Югыйсә бүген таш диварларга якын да килә торган түгел. Казан читендә әле нигезе дә казылмаган йортлардагы бер бүлмәле фатир бәясе 3–3,5 миллион сумнан башлана.

Милек эзләргә ярдәм итү белән шөгыльләнүче «Домклик» онлайн хезмәте аналитиклары агымдагы елның августында ил күләмендә беренче кертемнең уртача күләмен дә исәпләп чыгарган. Ул – милекнең 30,5 проценты, ягъни 1,6 миллион сум тәшкил итә, дигән белгечләр. Әлеге күрсәткеч барыннан да бигрәк Мәскәү (36 процент), Санкт-Петербург һәм Чувашиядә (һәркайсында 34 процент) зур икән. Ә иң түбән күрсәткечләр Хакасия (23 процент), Тыва һәм Якутиядә (һәркайсында 22 процент) теркәлгән.

Кредитлар кимегән

Татарстанда яшәүчеләр август аенда автомобиль сатып алуга барлыгы 3923 кредит рәсмиләштергән. Илкүләм кредит тарихлары бюросы мәгълүматларына караганда, бу – июльдәгегә караганда 3,6 процентка кимрәк. Җәй ахырында бирелгән автокредитлар саны буенча республика ил төбәкләре арасында 4 нче урынга чыккан. Беренче өч урында – Мәскәү, Мәскәү өлкәсе һәм Санкт-Петербург.

Сүз уңаеннан, Россия Банкының республикадагы бүлеге мәгълүматларына караганда, август аенда Татарстанда җиңел машиналар бәясе 4,38 процентка (июльдә 2,73 процентка) кыйммәтләнгән.

Кайда сез, эшчеләр?

Россиядә эшчеләргә ихтыяҗ арткан. Хәзер аны эшсезләр һәм эш эзләүчеләр хисабына гына канәгатьләндереп булмый. Хезмәт һәм мәшгульлек буенча федераль хезмәт җитәкчесе урынбасары Ян Талбацкий әйтүенчә, бу проблема бүген генә барлыкка килмәгән. Инде дистә ел буе эшче кулларга ихтыяҗ даими арта барган.

Иң күп вакансияләр – җитештерү өлкәсендә. Талбацкий сүзләренә караганда, эшче кулларга кытлыкны урта һөнәри уку йортларын тәмамлап чыгучылар хисабына бетерергә мөмкин.

Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы мәгълүматлары буенча, илнең IT тармагына 500–700 мең кеше җитми. Узган елда IT компанияләрдә хезмәткәрләр саны 13 процентка артса да, белгечләргә кытлык сакланып кала. Илдә бу тармакта 740 меңгә якын кеше эшли.

Таралмасын

Санитария табиблары коронавирусның яңа төре – «Пирола» таралу турында кисәтә. Роспотребнадзор хәбәренә караганда, «Пирола» өстәмә мутацияләргә ия һәм авыруның элеккеге төрләренә караганда йогышлырак. Әмма Россиядә аны ачыклау өчен тестлар, шулай ук чирдән нәтиҗәле дәвалану өчен дарулар бар.

Моңа кадәр бу вирус буенча Кытай һәм Швециядә тәүге тикшеренүләр дә уздырылган иде. Аларның нәтиҗәләренә караганда, коронавирусның яңа төре әллә ни йогышлы түгел һәм иммун системасын да «алдый» алмый.

Исегезгә төшерәбез: көз башланганнан бирле COVID-19 йоктыручылар саны ишәйгәннән-ишәя. 4–10 сентябрь чорында чирләүчеләр саны алдагы атнадагыга караганда 49,2 процентка арткан. Россия Хөкүмәт йортында, сезонлы чирләрне һәм коронавирусны кисәтү максатыннан, вакытлыча битлек режимы да керткәннәр. Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта бөтен ил күләмендә битлек режимын кертүгә сәбәпләр юк.

Һава торышы

Бәрәңгегә чыгар чак

Урамдагы һава торышына сөенеп туймассың! Җәйгечә коры, җылы һәм болытсыз көннәр тагын бер атна тирәсе дәвам итәчәк, ди синоптиклар. Ай азагына фаразлар да билгеле.

КФУ профессоры Юрий Переведенцев сүзләренә караганда, быел әбиләр чуагы бик вакытлы килде.

– Гадәттә, әбиләр чуагы бераз суытып алганнан соң, сентябрь уртасында башланырга тиеш. Быел нәкъ шулай. Кояшлы, җылы һава торышы тагын бер атна тирәсе дәвам итәчәк әле. Без киң антициклон йогынтысына эләктек. Ул көчле җилләр булмавы белән дә үзенчәлекле, – дигән ул.

Синоптиклар фаразларына ышансаң, бу атна ахырында һава температурасы урыны белән 27 градуска кадәр җылытачак. Явым-төшемнәр көтелми.

– Быел әбиләр чуагы бүленеп киләчәк, бу хакта алдан ук кисәткән идек, – ди Балтач районының Яңгул авылында яшәүче халык синоптигы Әмир Шәрәфиев. – Дүшәмбегә каршы төндә безнең якта термометр баганасы нибары дүрт градус җылы күрсәтте. Тик бу – вакытлыча гына күренеш. Быел әбиләр чуагы икегә, өчкә дә бүленеп килергә мөмкин. Сентябрьнең җылы булуының сәбәбе дә билгеле. Хәтерләсәгез, июнь салкынча булды. Гомумән, хәзер җәйнең бер өлеше сентябрьгә килеп керде. Һава торышы якынча унбер ел саен кабатланып бара. Җылы көннәр сентябрь беткәнче үк дәвам итмәс анысы, айның уртача һава температурасы барыбер якынча чагыша ул. Аерма күп дигәндә 1–2 градус тәшкил итәргә мөмкин. Ай башы җылы булса, ахыры салкынчарак булачак.

Халык сынамышлары

✓Көз озын килсә, яз соң килер.
✓Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килә.
✓Көз көне каен агачлары астан саргаеп, яфракларын астан коя башласалар – кыш җылы килә, ә өстән саргаеп, өстән яфрак коя башласалар – кыш салкын килә.

Әлегә исә айлык һава температурасы уртача күрсәткечләрдән 4–5 градуска югары, ди синоптиклар.

Әмир Шәрәфиев исә җылы көзне генә түгел, көзге эшләрне дә ашыктырмаска киңәш итә.

– Быел халык бәрәңгене дә бик иртә казыды. Августта ук бакчага чыктылар. Ул әйбәт түгел. Без бәрәңгене бу елларда гына алсак та, иртәрәк кебек тоелды әле. Августта бакча казырга киңәш ителми. Ашарга дигән бәрәңгегә ярый ул. Ә орлыкны саклыйсы да бар бит. Бәрәңгенең сорты бозыла, диләр. Иртә алганныкы ул. Җылыда бәрәңгенең «иммунитет»ы какшый, чыдамлыгы бетә. Ул суыкта чыныгу алырга тиеш. Мин хәтерлим әле: элек безнең бабай 14 сентябрь көнне бер чиләк бәрәңге казып, өй астына салып куя иде. Бер атнадан шуны төшеп карый да «иртәрәк әле, казымыйбыз» йә «казырга вакыт икән» дип нәтиҗә ясый. Шул рәвешле бәрәңгенең кабыгы ныгыганмы-юкмы икәнен тикшерә иде ул. Хәзер исә, корыда бәрәңгене җыеп алырга өлгердек, дип куаналар. Куанычы юк моның. Юка кабыклы бәрәңгенең файдасы шулкадәр генә, – ди халык синоптигы.

Сүзгә-сүз

duma.gov.ru

Яна ЛАНТРАТОВА, Россия Дәүләт Думасының Мәгърифәт буенча комитет җитәкчесе урынбасары:

Россия Мәгариф академиясе мәгълүматларына караганда, мәктәпкә килгән яшь укытучыларның 17дән алып 52 процентына кадәр беренче биш ел эчендә эштән китә. Төп сәбәпләрнең берсе – мәктәп җитәкчелегенең компетентлы булмавы. Шуңа күрә тәкъдим ителгән кандидатны директор вазыйфасына коллективның 75 проценты ризалык биргән очракта гына раслап куярга кирәк.

(«Парламентская газета»дан)

БӘХЕТ ӨЧЕН КҮПМЕ АКЧА КИРӘК?

SuperJob эш эзләү хезмәте халыктан шул хакта сорашкан. Россиядә яшәүчеләргә үзләрен бәхетле хис итәр өчен аена уртача 200 мең сум акча кирәк икән.

Ир-атларга >> **222 мең сум** • Хатын-кызларга >> **175 мең сум**

24 яшькә кадәрге яшьләргә >> **150 мең сум**
35 яшьтән өлкәнрәкләргә >> **222 мең сум**

Көзге туристлар

Казан көзен чираттагы ялны уздыру өчен иң популяр шәһәрләр исемлегенә эләккән. SuperJob үткәргән сораштыру нәтиҗәләренә караганда, Татарстан башкаласы бу җәһәттән Санкт-Петербург, Краснодар крае һәм Төньяк Кавказдан гына калышкан. Шулай ук Алтай крае һәм Кырым да көзге ялны уздыру өчен иң популяр юнәлешләр исемлегенә кергән. Ә инде башка илләр арасында Белоруссия, Төркия, Мисыр, Таиланд һәм Европа илләре атап үтелгән.

Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, илебездә һәр 10 кешенең өчесе чираттагы ялын көзгә калдырган. Шуның 15 проценты ялын өендә уздырачагын, 6 проценты бакчасына яки ил буйлап сәяхәткә юл тотачагын, 3 проценты чит илдә ял итәчәген белдергән.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АФРИКАДА КЫЗУ

Дөньяда сәяси һәм икътисадый турбулентлык дәвам итә. Якшәмбедән дүшәмбегә каршы кичтә Африкада чираттагы дәүләт түнтәрелеше турында хәбәрләр килде. Ил Президенты Нью-Йоркта чакта хәрбиләр Конго башкаласындагы төп объектларны кулга төшерде, диделәр.

Кызыгы шунда: Африкада ике Конго бар. Түнтәрелешнең кайсында икәнен беренче алынган кыска хәбәрләрдән аңларлык та түгел иде. Башкаласы Браззавиль булган Конго Республикасы сәяси тотрәнү кичерә икән. Африка өчен дәүләт түнтәрелешләре – гадәти күренеш, әмма соңгы айларда алар рекордлы санга иреште. Бер үзенчәлек бар: французлар яшерен коллыкта тоткан дәүләтләрдә тәхетләр әйләнеп каплана һәм гыйсъянчылар ачыктан-ачык Парижга дошманлык белдерә. Конго фетнәсенең рәвешен-төсен бу юллар язылганда әле әйтеп булмый. Илнең элемтә министры бернинди дә түнтәрелеш булмавын хәбәр итә.

Нью-Йорк дигәннән, бар дөньядан дәүләт җитәкчеләре шунда җыелды. Владимир Путин гына анда бара алмады. Алдагы көннәрдә БМО Генераль Ассамблеясында лидерлар чыгыш ясый. Үзара күзгә-күз очрашулар да уздырыла. Һәр дәүләт җитәкчесе үз иле мәнфәгатьләрен алга уткәрү өчен тырышлык куя. Зеленский АКШ сенаторлары алдында чыгыш ясарга да өзерләнә, мәсәлән. Эрдоган да актив очрашулар уткәрә.

Лидерлар үсешнең уртак сукмагын эзләп азапланганда, Кытай икътисады үзгәрешләр кичерә. Чин валютасы – юань 2008 елгы кризистан соң беренче тапкыр иң түбән дәрәҗәгә төште. Бер долларга хәзер 7,3 юань бирәләр. Россия үз резервларының төп өлешен чин акчасында саклый, димәк, резервлар саега. Әмма бу төп куркыныч түгел. Августта Кытай Үзәк банкы, милли валютаны тотып тору өчен, масштаблы күләмдә доллар сатты. Экспорт кими, дефляциядән качып, кытайлар төп ставканы төшерә. Россиядә һәм Көнбатышта ставка күтәрелгәндә, Күк асты илендә түбәнәя. Процентлар кимегәндә, гадәттә кредитлау арта, инфляция кечәя. Кытайлар болай да бурычлар сазлыгында инде. Юаньны йомшартып, алар экспортны арттырырга, бәя төшүдән котылырга тырыша. Бәя төшү – дефляция, чынлыкта халык өчен бик уңай күренеш булса да, процент капиталына корылган икътисад аны күтәрә алмый. Белгечләр Кытай юаненың мәтәлчеге бөтен дөнья базарлары өчен каракош ролен үтәр дип шикләнәләр. Россия өчен шәп түгел инде, анысын әзеп әйтергә була. Кытай товарлары үзләре өчен генә арзан, безнең өчен, алмый калмаячаклар дип, бәяне махсус күтәрәләр. Соңгы атналарда Кытай икътисады бераз җанланган. Илнең Тышкы эшләр министрлыгы бу унайдан «икътисад җимерелми» дигән белдерү таратты.

Россиядә

ИКЕ ЗОЛЫМНЫҢ ЯХШЫРАГЫ

Владимир Путин Россия икътисадының тотрыклылыгы турында белдерүләр ясаганда, илнең финанс системасы һәм җитештерүләр тармагы сизелерлек тетрәнүләр кичерә. Доллар курсының айкалуы һәм чайкалуы тотрыклылык турында сөйләми инде ул.

Үзәк банкның – үз кайгысы, ул һич тә Президент белән дуэт башкарырга теләми. Набиуллина ханымның үткән атнадагы Үзәк банк утырышыннан соңгы чыгышы экспортның түбәнәючәген, инфляциядән тиз генә котыла алмаячагыбызны, ә Үзәк банкның акча-кредит сәясәте дәвамлы рәвештә кырыс булачагын әйтә. Үзәк банкта кредитлау темпларының үсешеннән куркулары аңлашыла. Бүген акча өләшеп була ул, иртәгә түләү вакыты җиткәч, тәрсәкне тешләп булмый. Икътисад өстенә мул акча яңгыры яудыру җитештерүнең артуына бик үк китерми, кәчле инфляция һәм валюта мәтәлчеге генә китерел чыгара.

Без үткән атнада ук төп ставканың күтәреләчәген әйткән идек. Җомга безнең ул фаразны чынга ашырды: 12 процентлык ставка 13 процентка җитте. Финанс хакимиятләре югары ставканың озакка каласын яшерми, димәк, ил икътисадындагы тотрыклылыкка ышанмыйлар. Үзәк банк кадрлар дефицитының үсешне тоткарлаячагын рәсми рәвештә белдерә, мәсәлән. Үсеш юлында башка киртәләр дә җитәрлек. Төп ставканың күтәрелүе – шундый киртәләрнең берсе. Аның золым икәнен финанс регуляторы да яхшы аңлый, билгеле. Ләкин процентны күтәрмәсән, бәйдән ычкынган инфляция һәм девальвация көтә, дип уйлый. Аның бу фикеренең хаклыгын бензинга бәяләр үсеше дә раслый кебек. Әммә мотор ягулыгы төп ставканың күтәрелүен дә санга сукмый. Бу вазгыятьне без ел башында ук фаразлаган идек. Бензин – икътисадның каны ул, кан бозылса, тән дә бозыла. Авыл хуҗалыгы тармагы аеруча кыен хәлдә. Ашлыкка бәяләр төшә, ягулыкка һәм техникага арта, кредитлар да кыйммәтләнә. Бик зур золым бит инде бу, уйлап карасаң. Асфальтка укчә батыру белән бер. Финанс хакимиятләре ставканы күтәргәч, беренче ике золым юкка чыга дип уйлыйлар бит инде, өченчесе – кредитларның кыйммәтләнүе кечерәк золым дип санала. Шуңа күрә төп ставканы күтәрәләр дә.

Ләкин тәҗрибә шуны күрсәтә: беренче золым – инфляция беркая да китми, аңа икенче золым гына өстәлә. Бер Россия өчен генә түгел, глобаль икътисад өчен дә хас булган бу вазгыятьтән котылуның юлы юк. Икътисад турында сөйләгәндә, белгечләр «скукожиться» дигән терминны актив куллана хәзер. Икътисад җимерелми ул беркайчан да, җыерылып килеп кечерәя генә. Без шул процесска кереп ятабыз.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

УНБИШЕНЧЕСЕН КӨТКӘНДӘ

tatarstan.ru

Язгы эшләргә көзен нәтиҗә ясыйлар. Мәскәүдә Киләсе «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара форумының оештыру комитеты утырышы узды. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Рухи үсеш, туризм, кадрлар мәсьәләсен күтәрергә, икътисадка файдалы юнәлешләр турында да онытмаска – яңа форумга әзерлек бүгеннән башлана.

– Быел форумга кызыксыну зур булды, дөньяның 80 иленнән 16 меңләп кеше катнашты. Катнашучылар географиясе дә киң иде. Бу – БДБ илләре, Африка, Якын Көнчыгыш, Көньяк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия илләре. Форум мәйданчыкларында рекордлы күләмдә – 200ләп чара узды, 130дан артык килешү төзелде, – дип ассызыклады Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин. – Киләсе форум 2024 елның 16–17 маенда узачак.

«KazanForum» чарасының оештыру комитеты рәисе урынбасары, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, бүгенге вазгыятьтә Казандагы форум Россия һәм Ислам дөньясы илләренең икътисадый хезмәттәшлеге өчен төп мәйданчык булып тора.

– 2024 елда чара 15 нче мәртәбә узачак, – диде ул. – Форум кысасында Ислам дөньясы илләре белән хөкүмәтара комиссияләр утырышын оештырырга, шулай ук илебезнең дүрт төбәгендә – Татарстан, Дагыстан, Чечня һәм Башкортстанда ислам банкингын гамәлгә ашыру буенча нәтиҗәләр ясарга тәкъдим итәбез. Бүген бу – мәсьәлман дөньясы илләре белән үзара хезмәттәшлекне киңәйтү өчен әһәмиятле юсыл. Шулай ук даими катнашучыларыбызга рәхмәт белдерү һәм форумның 15 еллыгы уңаеннан махсус бүләк булдыруны да мөһим дип саныйбыз. «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеменең махсус утырышын оештыру нияте дә бар.

Чара өчен традицион булган тематик юнәлешләрне калдырып, аның эчтәлеген тагын да баетырга кирәк дигән фикергә килде утырышта катнашучылар.

Бу җәһәттән Татарстанның Инвестиция үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина:

– «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме утырышы, халыкара сәүдә-сәнгать палаталары форумы, хәләл ярминкә, мода фестивале кебек чараларны киләсе елда да саклап калырга кирәк дип уйлыйбыз. Төньяк-Көньяк транспорт коридоры, нефть-газ-химия тармагына, медицина хәләл туризмына багышланган сессияләр, ике ил арасындагы аерым сессияләргә (Россия – Азәрбайҗан, Россия – Малайзия) ихтыяҗ зур булды. Моннан тыш, инфраструктура, аерым алганда, тәэлеш һәм күчемсез милек, кадрлар әзерләү мәсьәләләре буенча темаларны көчәйтергә тәкъдим итәбез, – диде.

Марат Хөснуллин рухи якны да онытмаска өндәде. Әйтик, туризм, рухи үсеш һәм руханилар темалары буенча махсус чаралар уздыру мөмкинлеген карарга, кадрлар сәясәте кысасында югары уку йортларында укыту мәсьәләренә игътибар бирергә.

– Форумга кадәр әллә ни күп вакыт калмады, – диде вице-премьер. – Без барысы да форумны файдалы итеп үткәрүгә өлеш кертергә тиеш. Аның гамәли нәтиҗәсе булырга тиеш. Быел башкарган эшегез өчен һәркемгә рәхмәт белдерәм.

Билгеле булганча, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисад форумы Татарстан башкаласында 2009 елдан бирле уздырыла. Россия Президенты Владимир Путин карары нигезендә ул 2023 елдан федераль дәрәҗәдә оештырыла.

Татарстанга эш сәфәре белән Үзбәкстан Премьер-министры Абдулла Арипов килде. Рөстәм Миңнехановның сүзләренчә, бүгенге вазгыятьтә Казандагы форум Россия...

Татарстанга эш сәфәре белән Үзбәкстан Премьер-министры Абдулла Арипов килде. Рөстәм Миңнеханов белән берлектә алар «Алабуга» махсус икътисадый зонасын карады. Моннан тыш, Үзбәкстан делегациясе республиканың сәнгать һәм икътисадый потенциалы белән танышты. Казанга килер алдыннан Абдулла Арипов Мәскәүдә Россия Премьер-министры Михаил Мишустин белән очрашты.

Диңгез кирәкми

Туристка – ял, кешеләргә – эш, яхтага – тукталу урыны. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Туризм.РФ корпорациясе генераль директоры Сергей Суханов белән «Казан марина» курорты проекты турында фикер алышты. Идел ярында урнашачак әлеге курорт ел әйләнәсе эшләячәк, туристларны җәлеп итүче яңа урынга әйләнәчәк дип өметләнәләр.

Татарстан Рәисе әйтүенчә, әлеге проект республика өчен дә аерым әһәмияткә ия. Туризм һәм кунакчыллык индустриясен үстерү ягыннан караганда, әлеге курорт төбәккә туристлар агымын арттырырга ярдәм итәчәк.

Сергей Суханов Рөстәм Миңнехановка әлеге проектка карата булган игътибары өчен рәхмәтен белдерде һәм яңа территорияне үстерү комплексы ярдәм чаралары белән берләктә мөмкин хәл булуын ассызыклады. «Казан марина» курортлы өстенлекле инвестиция проекты дип танылды. Димәк, бу проектны гамәлгә ашырганда инвесторларга өстәмә ташламалар бирергә мөмкинлек туачак. Төп ярдәм чаралары, шул исәптән ташламалы кредит, инфраструктура төзелешен субсидияләү проектны нәтиҗәле гамәлгә ашыруны тәэмин итәчәк.

Белешмә өчен

- «Казан марина» курорты ел әйләнәсе эшләячәк.
- 72,8 га мәйданны биләячәк.
- 1250 номерлы кунакханә сафка басачак.
- 300ләп яхта кую урыны булачак.
- 1900 яңа эш урыны булдырылачак.
- Курорт «Бөек Идел юлы» төбәкара туристик маршруты үзәкләренең берсе булачак.

«Татар-информ»/«Туризм.РФ» корпорациясе

Җиңү

УК КЕБЕК

«СТРЕЛА» РОССИЯ КУБОГЫН ЯУЛАДЫ

Казанның «Стрела» командасы 17 сентябрьдә тәүге тапкыр регби буенча Россия Кубогын яулады. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов клуб президенты Алексей Песошинга, Татарстанның Регби федерациясе мактаулы президенты Айрат Шәфигуллинга, «Стрела» клубы директоры Рамил Вәлиуллинга, баш тренер Джейкобус Полус Нилга, команда коллективына котлау телеграммасы җибәрде.

«Хөрмәтле Алексей Валерьевич, Айрат Радинович һәм Рамил Әсхәтович! Хөрмәтле Нил әфәнде, кадерле уенчылар! Сезне Мәскәүдә PARI Россия Кубогы финалында зарыгып көтелгән тәүге җиңүегез уңаеннан котлыйм! – диелгән котлауда. – Барлык уенчылар һәм тренерлар, шулай ук регби спортына мөкиббән тугрылыклы җанатарлар белән команда өчен, гомумән, Татарстан спорты өчен чын мәгънәсендә тарихи вакыйга шатлыгын уртаклашам. Әлеге зур җиңүгә бик авыр һәм катлаулы юл үтелде. Бары тик остазлар, уенчылар һәм менеджерларның гаять зур уртак эше һәм команданың хәлиткеч уенда күрсәткән югары дәрәҗәдәге осталыгы, фидакарьләрчә уйнавы, ә иң мөһиме – гаять зур ихтыяры, ныгаять, зур җиңүгә китерде.

Шатлыклы хисләр бүләк итүегез һәм клубның казанышлары белән горурлану мөмкинлеге бирүегез өчен сезгә чын күңелдән рәхмәт белдерәм! Сезгә нык сәламәтлек, бәхет, спортта һәм тормышта уңышлар һәм яңа үрләр телим! Уклар кебек, бары тик алга!»

«Стрела» Мәскәүдә узган хәлиткеч матчта 23:12 исәбе белән Красноярскның «Красный Яр» командасыннан өстен чыкты. Бүләкләү тантанасында Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин да катнашты. Дүшәмбе иртәсендә җиңүчеләрне Казанның тимер юл вокзалында зурлап каршы алдылар.

Соңгы елларда башкала командасы зур сынаулар аша узды, хәтта бер мәлне аны таратырга да туры килде. Ә 2019 елда Алексей Песошин ярдәме белән «Стрела»га яңа сулыш өрделәр. Сүз уңаеннан, Хөкүмәт Рәисе әлеге клубның президенты, ул әле регби буенча спорт остасы да. Россия Кубогын откан команда хәзер инде ил чемпионы исеме өчен көрәшергә җыена.

«ҺӘРВАКЫТ ӘЗЕР!»

Дәүләт Советында

Татарстан парламентындагы КПРФ фракциясе чираттагы матбугат очрашуын уздырды. Фракция җитәкчесе Хафиз Миргалимов иң әүвәл илдәге, дөньядагы бүгенге вазгыятькә бәя бирде. Көнбатышның, Европа илләренең Россиягә һөҗүме дәвам итә, әмма без авырлыкларны җиңәргә өйрәндек инде, заман чакыруларына җавап бирергә һәрвакыт әзер, диде ул.

Татарстан Рәисенең Дәүсоветка еллык Юлламасы башкарма хакимият түрәләре, депутатлар өчен «өстәл китабы» булырга тиеш. Алай гына да түгел, Юлламадагы кайбер фикерләрне Россия Дәүмасы депутатлары да үз эшчәнлегендә файдалана ала, ди депутат.

Очрашу әнә шундый рухта башланып китсә дә, фракция депутатлары чыгышында күңел күтәренкелеге төшенкелек белән аралашып барды. Мәсәлән, яңа узган сайлауларда КПРФның уртача 15% тавыш җыюы, Россиянең берничә төбәгендә коммунистларның губернатор булып сайлануы – куанычлы хәл. Тик менә, мәсәлән, коммунистларның бүгенге сайлау системасына, аерым алганда, читтән торып электрон тавыш бирүгә каршы булуы уйландыра. Россия Дәүләт Думасы депутаты, актташыбыз Артем Прокофьев фикеренчә, электрон сайлау нәтиҗәләренең дөреслеген тикшерү мөмкин түгел.

Очрашуда катнашкан тагын бер депутат Фадбир Сафин яңа гына Минскида булып кайткан. Белоруссия башкаласын бик ошаткан, төзек, матур, ямь-яшел шәһәр, ди. «Бөке»ләр, түләүле парковкалар юк икән, ә менә Ленинга, аның көрәштәшләренә һәйкәлләр бар, берсенә дә кул тидермәгәннәр, ди. Аңлавыбызча, Белоруссия «кыргый капитализм»га бирешмәгән. Депутат бездәге мәгариф системасыннан риза-бәхил түгел иде. Ул Болонья системасы безне канәгатьләндерми, бердәм дәүләт имтиханы балаларны фикерләргә өйрәтми, ул – укучыны калдык-постык белемнән бәя бирү генә, ди.

КПРФ депутатлары, иң яхшы мәгариф системасы СССР вакытында иде, дип саный һәм берничә елдан «Көнбатыш реформасы» бездә юкка чыгарылачак, диләр. Карап карарбыз инде.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ЭШЛӘП ТАНЫЛГАН МӘКТӘП

Хезмәт тәрбиясе

Югары Ослан районының Матюшино мәктәбе, автокласс ачып, күрше авыл балаларына да һөнәри белем бирергә җыена. 37 укучы гына белем алса да, әлеге 11 еллык мәктәп тракторчы, тегүчеләр әзерләве белән аерылып тора. Технологик профильдә эшләүче уку йорты 2017 елда ил буенча иң яхшы авыл мәктәпләренең берсе булып танылды. Мондый уңышларга ул ничек ирешкән?

Яңа уку елыннан мәктәпләрдә хезмәт тәрбиясенә карата үзгәрешләр кертелде. Хәзер укучыларны такта сөрттерү, идән юдырту яки башка хезмәтләргә җәлеп итү өчен әти-әниләр ризалыгы кирәк түгел. Матюшино мәктәбендә моңа кадәр дә балаларны эшкә өйрәтүгә каршы килүчеләр булмаган. Биредә мәктәп яны участогы, ике теплица бар. Анда помидор, борыч, кыяр һәм башка яшелчәләр үстерәләр. Балалар тормышка әзер булып үсә. Кызлар сыер сава, чүкеч тота, техника иярли белә.

Исеме Матюшино дип йөртелсә дә, мәктәп Бакча-Сарай авылында урнашкан. Уку йорты күптән түгел 135 еллыгын билгеләп үткән икән. Мәктәп «Россия агромәктәпләре» берләшмәсенә кергән. 2014 елда һөнәргә өйрәтү үзәге ачканнар. Аны мәктәпнең элеккеге директоры Илдус Шәрәфиев җитәкли. Ул заманында тракторчы, экскаваторчы, комбайнчы, эретеп ябыштыручы булып эшләгән. Монда һөнәр үзләштерергә барлык урта мәктәпләрдән 9–11 нче сыйныф укучылары, шулай ук белемен күтәрергә теләгән тракторчылар килә. Башта мәктәп директоры Илдус Шәрәфиев, «УАЗик» машинасында җиде кешелек урын ясап, балаларны үзе ташыган. Аннан автобус бирелгән. Мәктәпнең килешү буенча алынган ике комбайны бар. Кыш көне күргәзмә буларак кулланылса, җәен укытучылар урак өстендә булыша.

Россия күләмендә грантлар откан кечкенә мәктәпнең тәҗрибәсе башка төбәкләр өчен дә кызыклы. Якутия, Иркутскидан ел саен мәктәп директорлары тәҗрибә уртаклашырга килә. Бу вакытта биредә республика семинары уза. «Россия авыл мәктәпләре энциклопедиясе» проекты җитәкчесе Николай Махнев та ерактан ишетеп килгән бу мәктәпкә. Уку йортының уңышлары аңа да бик кызык булып тоелган. Матюшино укытучылары үзләре дә бер урында гына таптанмый. Май аенда Казанда узган авыл укытучылары форумында «Авыл укытучысы нинди булырга тиеш?» дигән темага чыгыш ясаган.

– Балаларны авылда калдыру җиңел түгел. Механизаторлар картая. Алар заманча техникаларны бик аңлап та бетерми. Без, авыл баласы эшкә өйрәнеп үссен, дибез. Яшьләрне трактор йөртергә, комбайнда эшләргә өйрәтәбез. Алар документ алып чыга. Моннан ике ел элек тегү цехы ачтык. Югары Осланда яшәүче тегү остасы Ольга Аблаева һәр шимбә килеп белем бирә, – ди мәктәп директоры Римма Шәрәфиева.

Мәктәп яны интернаты эшли. Әти-әниләр соравы буенча быел урыннарны киңәйткәннәр. Ашханәгә федераль программа буенча ремонт ясалган, яңа җиһазлар белән баетылган.

Директор әйтүенчә, 12 укытучының җидесе – үзләренеке. Балалар төпле белем алып, вузларга укырга керә. Укучылар имтиханнарны әйбәт балларга тапшыра. ОБЖ буенча олимпиада җиңүчеләре дә күп. Узган ел Вәгыйз Фәйрушин Россия этабында абсолют җиңүче булып танылган. Санкт-Петербургтагы медицина-хәрби академиясенә укырга кергән. Хәрби табиб булырга җыена.

Укучылар патриотик тәрбияне дә яхшы аңлый. Мәктәпне 2003 елда тәмамлаган Фәнис Мөстәкыймов махсус хәрби операциядә катнаша. Танкчы егет: «Без дә сакламасак, туган җирне кем саклар?» – дип үзе теләп киткән. Хатыны – укытучы. Солдатларга укучылар белән хатлар язалар, бергәләшеп посылкалар җибәрәләр. Ялгыз әби-бабайларга булышу гадәте дә бетмәгән.

Автокласс булдыру – республика өчен яңалык. Әлбәттә, бу әле проект кына.

Фикер

Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ, КФУ галиме:
– Мәктәпкә хезмәт тәрбиясенең кайтуы бик кирәк иде. Советлар Союзында авыл һәм шәһәр мәктәпләрендә бу эш тигез алып барылды. Авылда мәктәп бакчалары, фермалары, урманчылыклары төзелде. Шәһәрдә һәр мәктәпнең үз теплицасы, хезмәт мастерское бар иде. Казанда зиннәтле, заманча мәктәпләр төзеп куялар, әмма аның тирәсендә чүл бураны уйный. Ни бер агач үсми, ни бер яшелчә түтәле юк. Мин директор булып эшләгәндә, уку йортында төрле гөлләр үсә, сандугачлар сайрый, ташбакалар йөри иде. Меңләгән куян асрый идек. Һәр мәктәпнең остаханәсе, теплицасы булырга тиеш.
Илебез таркалганнан соң хезмәт тәрбиясе юкка чыкты. Бөтен тәрбия Көнбатыш яшәү рәвешен, фильмнары, музыкасын пропагандалауга әйләнеп калды. Аның ни дәрәҗәдә зыянлы икәнен хәзер барыбыз да аңладык. Ни башы, ни кулы эшләми торган буын үсеп җитте. Кулына эш коралы тота белмәгән бала хезмәтнең кадерен беләмени? Бу бик зур хата иде. Моңа мәгариф өлкәсендә эшләүче укытучылар, директорлар бик борчылды. Бөтен норматив документлар балаларны эштән биздерүгә юнәлдерелгән иде. Такта сөрттермәскә, сыйныфта – гөл, мәктәп тирәсендә түтәлдә әйберләр үстермәскә… Укучы бернәрсә дә эшләмәскә тиеш. Баланың эчке рухи халәтен менә шулай ничә еллар буена сындырдык. Яшьләрне таркату бара. Мәктәпкә барсаң, тизрәк чыгып качасы килә. 11 нче сыйныфка җиткән егетләрнең чәчләре ак, зәңгәр, яшелгә буялган. Чәчләрен кызлар кебек үреп йөрүче малайлар күп.
Хезмәт тәрбиясе булмагач, һөнәр сайлый белмиләр. Әгәр законда булса, әти-әниләр балаларын мәктәптә эшләтүгә каршы булмас иде. Хәзер хезмәт тәрбиясе кире кайтарылды. Соң булса да, уң булсын!

Әмма көзге каникулда аны тормышка ашыра башламакчылар.

– Хәзерге вакытта автобусны заманчалаштырып җиһазландыру эше бара. Анда телевизор, ноутбук, өстәл урнаштырылачак, – ди Римма Шәрәфиева. – Балаларны районның бер башыннан икенчесенә йөртү авыр. Ягулыкка да шактый чыгым китә. Каникул вакытында укытучылар автобус белән күрше авылларга барып укытачак. Булачак механизаторлар 3–4әр сәгать лекция тыңлап, видеофильм карап белем туплый ала. Тегү буенча да шулай. Күрше авылдан безгә килүче сәламәтлеге чикләнгән балаларга да уңайлы булачак бу.

Сәрия МИФТАХОВА

Рәсми хәбәр

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Авиатөзелеш районында урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:50:221305) 30 июнь, 2023 ел, № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Волгоград урамы, 32 й. (телефон: +7 843 223 22 33), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары хакимиятләренең (https://kzn.ru/meriya/administratsii-rayonov/avianovsav);

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитетының (https://rosreestr.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 10 октябрендә (14 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Волгоград урамы, 32 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 19 сентябреннән 2023 елның 10 октябренә кадәр һәм 2023 елның 10 октябреннән 2023 елның 13 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Колай авыл җирлегендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:33:051601) 30.06.2023 № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Колай авылы, Профсоюз урамы, 24а й. (телефон: (8-84367)36-5-25, 36-5-80), яки Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы хакимиятенең https://pestreci.tatarstan.ru;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 10 октябрендә (08 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Колай авылы, Профсоюз урамы, 24а й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 19 сентябреннән 2023 елның 10 октябренә кадәр һәм 2023 елның 10 октябреннән 2023 елның 13 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районында урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталлары номерлары 16:50:240201, 16:33:021144, 16:50:250202, 16:50:240202, 16:50:140423) 30 июнь, 2023 ел, № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Шуртыгин урамы, 1 й. (телефон: +7 843 223-20-00), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Казан шәһәре Башкарма комитеты Совет районы хакимиятенең (https://kzn.ru/meriya/administratsii-rayonov/sovetskiy;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитетының (https://rosreestr.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 10 октябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Шуртыгин урамы, 1 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 19 сентябреннән 2023 елның 10 октябренә кадәр һәм 2023 елның 10 октябреннән 2023 елның 13 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы прокуратурасының прокурорларның гражданлык һәм арбитраж процессларында катнашуларын тәэмин итү бүлеге башлыгы **Гудкова** Екатерина Геннадьевнага, Татарстан Республикасы прокуратурасының кадрлар бүлеге башлыгы **Хөснуллина** Ирина Геннадьевнага, Татарстан Республикасының «Буа урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесенең Буа участок урманчылыгы урман мастеры **Данилов** Борис Алексеевичка **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

***

Эшендә ирешкән уңышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсенең оештыру бүлеге башлыгы **Ибраһимов** Җәүдәт Хәмзә улы, «Татарстанның элиталы орлыклары» бөртекле культуралар орлыклары җитештерү ассоциациясе оештыручысы зона агрономы **Миңнуллин** Рафаил Мөгаллим улы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аппаратының план-финанс бүлеге консультанты **Рәхмәтуллина** Гөлнар Рәдиф кызы, «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары **Хәбибуллин** Наил Изәт улы; күпьеллык намуслы хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы советы әгъзасы **Тухфатуллов** Мансур Шаһи улы; җәмәгать туклануы системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Тимерхан» бизнес үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ашханәсе шеф-повары **Хәйбуллов** Радик Наил улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Әхмәрова** Гөлзадә Рафаил кызы, хезмәт ветераны **Камалов** Булат Вагыйзь улы; югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы, республиканың дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсенең чараларга хезмәт күрсәтү һәм биналарны карап тоту бүлеге I категорияле белгече **Сабирҗанов** Рәмис Гомәр улы; Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүе өчен вокалчы артист (солист) **Хәлимова** Зөһрә Нигъмәтулла кызы (Зөһрә Шәрифуллина) **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты җир-мөлкәт мөнәсәбәтләрен координацияләү һәм үстерү бүлеге баш киңәшчесе **Казаков** Олег Виссарионовичка **«Татарстан Республикасының атказанган җиртөзәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасының «Кайбыч махсуслаштырылган орлыкчылык урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе Урсак җитештерү участогы урман мастеры **Адиятуллин** Айрат Гомәр улына, Татарстан Республикасының «Зәй урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Болгар участок урманчылыгы участок урманчысы **Рәхмәтуллин** Рафис Нигъмәтҗан улына **«Татарстан Республикасының атказанган урманчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Казан шәһәренең «Ракета» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тренеры-укытучысы, «Татарстан Республикасының бильярд спорты федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма директоры **Белов** Алексей Владимировичка, Чаллы шәһәренең «Төзүче» спорт мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе тренеры-укытучысы **Мадияров** Марат Ягсып улына **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәяләр кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесенең төзелештә бәяләр кую идарәсе башлыгы урынбасары **Әхмәтшина** Чәчәк Сәлим кызына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы керемнәрне планлаштыру һәм анализлау бүлеге башлыгы **Гыйзетдинова** Зөлфия Гыйззәтулла кызына, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының икътисад, дәүләт заказын урнаштыру һәм түләүләрне администрацияләү бүлеге башлыгы **Корбанов** Азат Шәйхетдин улына, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Перспективалы үсеш үзәге директоры урынбасары – Үзәкнең бүлек башлыгы **Смольникова** Елена Владимировнага, «Эссен Продакшн АГ» акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары **Цыпленков** Александр Викторовичка, Татарстан Республикасы Хисап палатасының экспертиза һәм методология идарәсе инспекторы – методология бүлеге башлыгы **Вилков** Игорь Геннадьевичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратының контроль-ревизия бүлеге башлыгы **Шәрифуллин** Равил Әнәс улына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.



ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ



Наил ШӘРИФУЛЛИН

«Санлы» дөнья сансызлыклары

Андроидка – 15 яшь. Һәркемнең дә диярлек кесәсендә яисә кулында йөргән хикмәтле җиһаз – смартфонның җаны, эчендәге җене һәм пәрие, аның төп инструкция-программасы балигълык яшенә якынлаша. Телефонга куелган, рәсми телдә «операцион система» дип аталган ул хикмәт булмаса, дөньяны үзгәрткән, адәми зат көненә йөз тапкыр баккан кесә әсбабы пластмасса, металлдан, ярымүткәргечләрдән торган кирәксез бер нәрсәгә әверелер иде.

«Җен» чүлмәккә, ягъни кесә телефонының смартфон дип аталганына 2008 елның 23 сентябрендә җайлап кереп урнаша. Шушы көнгә кадәр чыгарга җыенганы юк. Чыкмаячак та. Экранны көне-төне ышкып, без аны кушканны эшләргә генә мәҗбүр итәбез. Тыңлаулы ул – безнең теләсә кайсы теләгебезне мизгел эчендә үти дә куя. Сөйләшү, язышуны кесә телефоннарының күпкә гади булганнары да башкарды. Тик без бит нәфеслеләр, туймас тамаклар – безгә ул гына аз. Безнең теләсә кайда – урамда, транспортта, кибеттә, хәтта мунчада да интернетка керәсебез, мессенджерларда фотолар алышасыбыз, социаль челтәрләрдә утырасыбыз килә. Күндәм һәм үтә дә җитез «җен», ягъни программа барысын да эшли генә түгел, аның әле ел саен диярлек әллә күпме опция-мөмкинлекләр өстәлгән яңадан-яңа версияләре дә чыгып тора. Ул гынамы, без әйткән ул платформа әле тагын планшетларга, фитнес-сәгатьләргә, телевизорларга, кайбер ноутбукларга да куела һәм эшли.

Язуларынча, адәми зат кулыннан төшерергә бик яратмаган җиһаз – телефонны мең дә бер төрле функцияле итәчәк ул программаны беренче башлап Android Ins дип аталган Америка компаниясе 2005 елда әвәләргә алына. Бераздан аны күбебез тагын да шул телефон аркасында яхшы белгән Google сатып ала. Бүгенгә операцион системаның инде 14 версиясе эшләнгән һәм кулланучыга тәкъдим ителгән. Һәр версия эчендә әле тагын да версия-вариантлар барын белгәндә, берсеннән-берсе камилрәк йөзгә якын төр «телефон пәрие» килеп чыга. «Пәри» бәясе телефон бәясенә кертелгән, теләсә кайсын сайлап ала аласың. Дөньяда чыгарылган барлык смартфоннарның 80 процентган артыгының эчендә бүген без сөйләшкән программа – Андроид утыра. Кыйммәтле, элиталы смартфон – «Айфон» (iPhone) «җене» булган iOS дип аталган операцион система, таралышы буенча, без әйткән программаны беркайчан да куып җитә алмаячак. «Айфон» – кыланчыклар һәм мактанчыклар телефоны. «Җене» уңган-булганрак саналса да, артыгын кыра алганы юк әле...

Цифрлашу, ясалма интеллект, башкасы хакында бүген күп сүз сөйләнелә. Технологияләр шактый азынган заманда яшибез, башкача була да алмыйдыр. Кайчакта, хәерлегә генә булсын инде барысы да, диясе дә килә. Ни өчен дигәндә, техник һәм технологик алгарыш олы адымнар белән алга атлаганда, рухият өлкәсе урында таптана яисә алга артык акрын бара. Дөньялар тыныч түгел. Цифрлы технологияләрнең исә тыныч тормышка эшләмәгәннәре әле күбрәк тә. Адәми затның холыкфигыле шундый, ниндидер олы гарасатка килеп җитмичә ул туктамаска да мөмкин. Бүгенге мәгълүмат ташкыны, аның башлыча негатив кимәлдә булуы да һич тә файдага түгел. Технологик прогресс бераз акрынайсын, әхлак, иман, шәфкать, миһербанлылык дигән кыйммәтләр алга чапсын иде дә бит. Юк, әлегә киресенчә...

Андроид булсын, ул куелган бүгенге телефоннар, гаджетлар, кайбер компьютерлар, заманча телевидение булсын, барысы да – цифрлашу нигъмәте. Ул шаукым хакында, әйткәнебезчә, бүген ялкау гына сөйләми, язмый, күрсәтми. Газета укучыларга, шул өлкәгә караган белгечлек иясе буларак, аның асылы хакында кайбер ачыклыклар кертәсем килә. Цифрлаштыру нинди мәгълүмат бар, барысын да элемтә каналлары аша санга әйләндереп, кирәк җиргә озату, кабул итү, санлы форматта эшкәртүне аңлата. Ә андый матавык, ахыр килеп, һәрдаим электроникага, электрон технологияләргә барып тоташа. Санга әйләндерү саннар санап утыру түгел, ул – барын да икеле санау системасына күчерү. Икеле санау системасында барысы ике генә сан бар: 1 һәм 0. Ягъни чипның, микросхеманың кайсыдыр «тәпи»ендә сигнал йә бар, йә юк. Видеомы ул, фотомы, текстмы, санлы мәгълүматмы – һәммәсе шундый рәвешкә – 0 белән 1дән генә торган комбинациягә китерелә.

Ни өчен? Чөнки алай эшкәртү дә, кабул итү дә, озату да нык җайлы. Цифры халәттә саннар да гел башка: 10 – икелене, 11 – өч санын, 111 сигезне аңлата. Сүзләрне, мәсәлән, «мин сине яратам»ны цифрлаштырсак, 30дан арткан «0» һәм «1»дән торган су буе сан килеп чыга. Цифрлашу шундый күп урынлы саннар белән эш итүгә кайтып кала да инде. Кабул ителгән су буе саннар, кирәк чагында – кешегә ирештерергә кирәк булганда, янәдән гадәти рәвешкә кайтарыла. Шул ук фотографияне, мәсәлән, меңәрләгән саннарны укып аңлау, күрү мөмкин түгел бит. Ике кеше телефоннан сөйләшкәндә исә, трансформация, ягъни саннарга күчү, телефонына карап, булырга да, булмаска да мөмкин. Белгечләр аналог калыбы (аналоговый сигнал) дип атаган форматта эшләгән телефоннар да әлегә бар. Тик кемдер диалогны диктофонга яздыра икән, тагын да шул цифрлар кулланыла...

Цифрлашу кирәк, мөһим. Тик ул юнәлешкә кереп киткәндә, бераз як-якка карану, аның зарарлы якларын ачыклау да үтә мөһимдер. Шул ук Андроид, кесә телефоннары өлкәннәргә, бәлки, ярап та торадыр, тик бала, аның физик һәм рухи сәламәтлеге дигәндә, ул – бәла. Халык моны әле аңлап җиткерми. Аңлагач, соң булмасын иде. Смартфон – глобальләшүнең дә нәтиҗәле ярдәмчесе, колы. Без – татарны, бигрәк тә балаларыбызны туган теленнән, милли мохиттән аралаучы да шул. Гыйлем чишмәсе – китаптан халыкны биздерү дигәндә дә аның роле бик зур. Бу яклардан караганда, санлы технологияләр, санлы дөньяга карата «сансыз» сүзен, сыйфатын куллану да урынлы кайчак.

БӘГӘРӘК ТАМАГЫ ТЕЛНЕ САКЛЫЙ

Чиләбе

Милләттәшләр

Чиләбе өлкәсенең Кунашак районындагы Бәгәрәк Тамагы авылында татар телен саклау һәм үстерү буенча җирле иҗтимагый оешма төзелде. Бу оешма Урал тауларындагы татар авылларында яшәүче күп кенә милләттәшләребезне берләштерер дип ниятләнә.

Чыннан да, бу җирдә татар авыллары күп, тарихлары да бай. Сәнәр белән Бәгәрәк елгалары кушылган урында җәелеп утырган Бәгәрәк Тамагының да 315 еллык тарихы бар. Елга буйлап урнашкан урамны үлчи китсәң, озынлыгы 8 чакрымга җитә. Ул хәзер Муса Җәлил исемен йөртә. Җирле үзидарәгә тагын 13 авыл керә. Алар арасында Күмкүл, Сәнәр, Усман, Ихсан дигән күңелгә ятышлы бик матур исемнәр бар. Тарих битләрендә бу авыллар 1708 елда барлыкка килгән дип саналса да, архив документлары вакыт-вакыт әлеге санның ялгыш икәнлеген дәлилли. Мәсәлән, Усман авылының бу төбәктә 1670 елда ук яшәгәнлеге турында мәгълүматлар табылган.

Бәгәрәк Тамагының бүгенге хәле сер бирә торганнардан түгел, әлбәттә. Әмма саннарга карасак, һәр җирдәгечә, анда да кайчандыр «упкынга төшеп китү» күренеше булганын шәйләргә була. Хәзер авылда Сәнәр елгасы аша ике күпер салынган, мәчет эшли. Тагын икесе төзелеп ята. Ә 1917 елгы инкыйлабка кадәр монда җиде мәчет эшләгән. Мәктәп белән дә шул ук күренеш. Хәзер берәү эшләп килсә, элек алар икәү булган, өстәвенә һәр авылда (Бәгәрәк Тамагы өч авыл кушылудан барлыкка килгән) башлангыч мәктәпләр эшләгән. Авылның үз китабы да бар. Аны Бөтендөнья татар конгрессының Төбәкчеләр оешмасы җитәкчесе Альберт Борһанов язган. Ул үзе дә шушы җирдә туып-үскән. Туган якның тарихын өйрәнү өчен вакытын да, көчен дә җәлләми. Балачактан тарих белән кызыксынып яшәгән. 1960 нчы елларда ул бакчаларында 1652 елда сугылган голланд тәңкәсе тапкан. Бәгәрәк Тамагы тирәсендә Сәнәр елгасы буйлап 13 археологик һәйкәлнең дә «эзенә төшкәннәр». Шунысы сөендерә: эзләнүләр нәтиҗәсендә китаптагы мәгълүматлар да арта бара.

Хастаханәләр белән дә шул ук хәл. Элек алар икәү булган. Берсе – өлкә әһәмиятендәге туберкулез хастаханәсе. Хәзер исә аның урынында фельдшер пункты белән даруханә урнашкан. Кунашак җитәкчеләре әле анысын да ике тапкыр (2012 һәм 2023 елларда) япмакчы булган. Әмма авыл халкы нык торган. Иганәчеләр табып, хастаханәне үзләре төзекләндергәннәр. Бу җәһәттән шунысын да әйтик: архивтан күренгәнчә, авылда фельдшер участогы 1873 елдан бирле эшләп килгән. Димәк, быел аның 150 еллыгын билгеләп үтәргә тулы нигез бар дигән сүз бу. Тарихи булгач, авылда юбилейлар бер-бер артлы булып кына тора. Узган ел мәктәпнең 100 еллыгы уңаеннан Бөтенроссия фәнни-төбәк конференциясе үткәрелә. Авылны мәктәпле итүче беренче директор Җамалетдин Камаловка истәлек тактасы да куела. Остаз педагогның үзенең дә 140 еллык юбилеен билгеләп үтәләр. Бәйрәм хөрмәтенә мәктәп янында, авыл үзәгендә асфальт юл түшиләр. Кунашак хакимияте белән җирле эшмәкәрләр мәктәпнең актлар залын ремонтлый. Татарстан Республикасы исеменнән Бөтендөнья татар конгрессы музыкаль үзәк белән китапханә өчен китаплар, дәреслекләр бүләк итә.

Авыл халкы үзен дә, телен дә, гореф-гадәтләрен дә хөрмәт итеп, аякка нык басып яши. Шуңа күрә бу милли байлыкларны саклау эшенә дә үзләре теләп алынуы гаҗәп түгел. Иҗтимагый оешма советы рәисе, Бәгәрәк Тамагы төбәк музее мөдире Эльза Газизова элек җирле үзидарәне җитәкләгән. Заманында авылны һәр яклап үстерү өчен зур эшләр эшләгән. Бүген авылдагы җәмигъ мәчете төзелешенә дә җитәкчелек итә.

Ә яңа оешма эшен мәктәптәге татар теле кабинетын яңартудан башлаган. Диварларны, түшәмне яңартканнар, идәнгә плитә тезгәннәр, яңа яктырткычлар, тәрәзә пәрдәләре элгәннәр. Бу эшләрнең барысын да җирле эшмәкәрләр белән авыл халкы башкарып чыккан. Район мәгариф идарәсе яңа җиһаз белән тәэмин иткән. 1 сентябрьгә укучыларга зур бүләк булган бу. Дәреслекләр белән методик әдәбиятлар җитеп бетми икән җитүен, әмма укытучылар бу җәһәттән Татарстанга зур өмет баглыйлар. Иң мөһиме – кылган гамәлләренә рухланып яшиләр. Монда инде тел бетә, гореф-гадәтләрне югалтабыз дип зарланырга урын юк. Барысы да үзебездән тора, димәк.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

«ӘЙТЕРСЕҢ, ГОМЕР УЛ – ТАУ ЮЛЫ...»

Авыл җаны

Минем бүгенге виртуаль авылдашым – Актаныш ягыннан, Татар Суыксуы авылыннан Роберт Сәләхиев. Бик күпләр аны шагыйрь, җырлар авторы буларак белә.

Татар халкы шигъри күңелле бит ул: аның һәр авылда диярлек үз җирле шагыйре яки шагыйрьләре була. Дөрес, бөтен шигырь язучы әле ул әдәбият дөньясына ниндидер яңалык алып килүче шагыйрь дигән сүз түгел. Ләкин үз җирлегендә аның халыкка йогынтысы, тәэсире бик күп кенә исемле шагыйрьләрдән дә зуррак була. Ул бит – үз кеше, таныш кеше. Аның шигырьләре дә гади, аңлаешлы. Роберт абый – Язучылар берлеге әгъзасы, бу инде – зуррак дәрәҗә, зуррак абруй, киңрәк даирәдә танылу дигән сүз.

«Без яшь вакытта хәзерге кебек уңайлыклар булмаса да, авыл шаулап тора, гөрләп яши иде. Без коммунизм төзедек – максатлар зурдан иде. Аннан соң, әти-әнине карамыйча, төп нигезне ташлап, каядыр бәхет эзләп чыгып китү минем өчен хурлык иде», – ди ул.

Авылда яшәүнең уңай яклары һәм уңайсызлыклары турында сөйләшәбез. «Бөтен уңайлыклар бар: утысуы, газы кергән, урамнар якты, төзек». Чынлап та, Татарстандагы авыллар турында сөйли башласак, күп очракта шулай бит. Кызганыч, авырткан сөял дә бер төрлерәк: «яшьләргә эш юк, күмәк хуҗалыклар таралды. Безнең авылда гына ничә оешма бар иде, аларның берсе дә юк».

Авылымның бүгенге хәле бик борчый, ди ул. «Мәктәпкә бер бала үтеп китә минем урамнан! Югыйсә яшәргә бөтен уңайлыклар бар, ә яме юк...» Шагыйрь буларак очрашуларга йөргәндә, татар баласының тел-әдәбият белән кызыксынуы азаюына, аларның аңын интернет-телефонның биләп алуына да йөрәге әрни.

«Нинди ул бүгенге авыл кешесе?» – дип сорыйм Роберт абыйдан. «Авылда хәзер бу тормышка кул селтәгән, бар әйбергә дә битараф әбиләр дә бабайлар. Эшли алганы азрак мал-туар асрап үз көнен үзе күреп яшәп ята. Алары да безнең буын кешеләре бит инде, олыгаеп баралар».

Авылны саклап калу – авыр мәсьәлә, дип саный Роберт абый да. «Бөтен җирдә дә, Россия буенча да бер үк төрле хәл. Авыллар картайды. Картлыктан соң нәрсә килә?» Әйе, риторик сорау гына түгел инде бу. Картлыктан соң ни килүен барыбыз да белә.

Шулай да, шагыйрь күңеле хыялыйрак бит инде ул. Берәр төрле олы үзгәреш килеп туса, дөньялар яхшы якка да үзгәрер кебек.

Бүген балалары, оныклары исән-саулар, кайтканнарын көтеп ала, озатып кала Роберт абый. «Иң зур шатлыгым шул», – ди ул.

Күпчелек вакытын бакчада казынып, чәчәкләр, яшелчәләр үстереп үткәрә. Умарталар асрый: умарта күп хезмәт сорый, вакыты шулар белән үтә. «Бал кортыннан күбрәк эшләмәсәң, бал алып булмый ул».

«Җәй көне бик китап укып утырып булмый», – ди «Китап укыйсызмы?» – дигән соравыма. Социаль челтәрләргә куйган шигырьләр дә кич кенә язылалар икән. Ә социаль челтәрләрдә шактый актив ул: заман белән бер адымда атларга тырыша; уй-хисләре белән бүлешә. Хыялга килсәк...

«Кояшына гашыйк көнбагыштай,
Гашыйк булып яшим дөньяга.
Шуңадырмы, барлык хыялымның
Юлларында яшел ут яна», –
дисә дә...

«Якты хыялларым – Татарстан китап нәшриятына моннан өч ел элек бирелгән (берсе – зурлар, икенчесе балалар өчен) китапларымны күрү. Татарстан китап киштәләрендә балалар өчен китап аз, дип лаф оралар, ә язылган әйберләр тузан җыеп ята», – дип көрсенә шагыйрь.

Роберт абый озак еллар агроном булып эшли. Җиргә иң якын кешеләрнең берсе. Шуңа да җирнең-авылның акрын гына хәлсезләнә баруына да нык эче поша, әлбәттә. Яшьләрнең тормышларын җиргә бәйләргә теләмәүләрен күреп сыкрана. «Нинди генә программа уйлап тапсалар да, шәһәргә барып урнашкан, дөньясын яхшы шартларга көйләгән яшьләр авылга кире кайтмаячак инде, кайтса да, кунакка гына кайтачак», – дип көрсенә.

«Якты өметләрем сүнгән көнне
Сабырлыклар сорыйм Алладан...» –
дип, бик күпләрнең уйларын сеңдергән шигырьләр яза.

Авыл кешесенә сабырлык бигрәк тә кирәктер ул бүген. Әллә киресенчә микән?! Әллә шулай сабыр, түзем булганлыгын белгәнгә күрә тиресен дә салдырырга әзер торалармы? Әллә бердәм, берәгәйле сүз кирәкме?

Лилия ФӘТТАХОВА

Шөгыль

Теләче

МАТЕМАТИКА УКЫТУЧЫСЫ:
«БАЛ КОРТЛАРЫН УКЫТАМ»

Теләчедә яшәүче Нияз Сабирҗанов һөнәре буенча – укытучы. Әмма табигатьне, туган җирен ярату аны авылга кайтара. Үз бәхетен, яраткан эшен дә ул биредә таба.

– Казанда укыдым. Студент чагымда да шәһәрне яратмый идем. Шимбә җиткәнен дүрт күз белән көтеп тора идем. Укып бетергәч, әтием белән эшли башладым – умарталыкка юл тоттым, – ди Нияз. – Әтием Нуриман 1980 елдан бирле бал кортлары тота. Мин – умарталыкта үскән бала. Апам да, энем дә бу шөгыльне сайламады, ә менә миңа бик ошый.

Әтисе Нуриман абыйны республикада күпләр белә. Аларның балын бер татып караган кеше даими сатып алучыга әйләнә. Умарталары да җитәрлек. Бүген 300дән артык умартабыз бар, ди Нияз.

Заманында Нуриман абый да агрономлыкка укырга дип чыгып китә. Әти-әнисе теләгенә каршы килми ул. Әмма уенда гел авылы була. «Укырга керә алмасам иде», – дип тели. Шулай була да – имтиханнарны тапшыра, әмма бер баллы җитми. Сөенәсөенә авылына кайтып китә. Башта колхозда төрле эшләрдә эшли, аннан соң умартачылык белән шөгыльләнә башлый. Бал кортларының телен яхшырак аңлар өчен укып та кайта. 1986 елда Фәймә апа белән тормыш кора.

Теләчелеләр аларның үзләрен дә бал кортына тиңли. Бер дә ару белмәс, тик тормас, диләр Сабирҗановларны.

– Без урта рус токымлы кортлар асрыйбыз. Алар салкынга да чыдам, авыруларга да бик бирешмиләр. Балны да тырышып җыялар, – ди Нияз. – Умарталарыбыз дүрт җирдә тора. Авыл эчендәгесе дә бар, урмандагысы да, басуга да куйдык. Быел елына карап уңышы яхшы булды. Зарлана алмыйбыз. «Ник бу эшкә тотындык?» – дип бер дә үкенгәнебез юк. Умарталыкта күңелем ял итә. Урманга чыгып китеп, рәхәтләнеп йөрим. Дөрес, кортлар сөйләшмәсә дә, аларны күзәтү үзе бер рәхәтлек бирә. Кеше, арыдым әле, дип ятып тора ала, ә бу кортлар – гел эштә. Бигрәк тырыш алар. Яңгыр явасын да кортларга карап беләбез. Явым-төшем көтелсә, күчләре белән кире әйләнеп кайталар алар.

Сабирҗановлар бал гына сатмый. Алар төрле файдалы төнәтмә, крем, бәлзәмнәр дә ясый башлаган. Прополис, корт анасы сөте (маточное молочко), үлгән кортлардан ясалган төнәтмә, бал икмәге (перга) сорап килүчеләр шактый икән.

– Хатыным декретта утыра. Уйлаштык та, әллә балдан сабын, кремнар ясап карыйкмы, дидек. Булдырдык бит. Үз балаларыбыз да кечкенәдән бал ашап үсә. Бал икмәген дә сорап кына торалар. Әмма арада иң файдалысы – ана корт сөте. Аны күбрәк өлкән яшьтәгеләр ала.

Нияз кортлар турында бик яратып сөйли. Җаны-тәне белән туган ягын яратучы кеше ул. Күңеленә рәхәт эше бар. Гомердә дә авылымны шәһәргә алыштырмас идем, ди.

– Казанга барып килгәндә дә арып кайтам. Анда бит гомернең яртысы «бөке»дә уза. Ә монда рәхәт. Урманда «бөке»ләр юк. Үз җаеңа эшлисең. Мине әллә кайларга чакырдылар. Шәһәр мәктәпләрендә дә эш бар иде. Китмәдем, – ди ул. – Әти еш кына, кортларга математика укытасың инде, ди. Бал кортлары теләсә кемгә эшләми ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЕ

Хушлашу

Татар җәмәгатьчелеге кабат зур югалту кичерде. Татарстанның халык артисты, моңлы җырчы Флюра Сөләйманова бакыйлыкка күчте. Аны Казанның Мәрҗани мәчетеннән соңгы юлга дога һәм алкышлар белән озаттылар.

Тыйнак, зыялы, зәвыклы, гайбәткә кермәс, беркемгә дә каты бәрелмәс зат. Хушлашу мәрасименә җыелган шәхесләр аны әнә шушы сүзләр белән искә алды. Хәтта данлыклы «Әниемә» җырын көйләп торучылар да очрады. Хушлашканда шәхес турында «иде» сүзен кулланып сөйлибез. Флюра Сөләймановага карата бу сүзне һич кенә дә кулланасы килмәде.

«Институтны күреп булса да китәрмен, диде»

Җор телле, юморлы кеше. **Баянчы, Татарстанның халык артисты Кирам Сатиев** Флюра апа белән булган кызыклы истәлекләрне барлады.

– Флюра апа белән дистәләрчә еллар бергә Филармониядә эшләдек. Мин аның кем беләндер әйткәләшкәнен, низагка кергәнен белмим. Бу аның нинди кеше булуы турында сөйли, – диде баянчы. – Беләсезме икән, юкмы, Флюра апа бик юмор хисле кеше иде бит ул. Бервакыт Флюра апа шалтырата. «Кирам, энем, иртәгә концерт, яңа җыр кирәк, кайда очрашабыз?» – ди. Мәдәният институтында укытам, шунда килә алмассыңмы, дим. Миңа җавап итеп: «О, бик әйбәт булыр, мин бит институтларда укыган кеше түгел. Күреп булса да китәрмен!» – диде. Институтта очраштык. Шул арада уку йортында «Флюра Сөләйманова килгән!» дигән сүз таралып өлгергән. Эшебезне бетереп, кире чыкканда, студентларым аның белән фотосурәткә төшәргә теләвен әйтте. «Сез бит легенда, Флюра апа, төшик инде», – диләр. «Чәчем дә матур түгел, прическам да ясалмаган инде… Әйдә, ярар, балаларны куркытырга булса да ярар бу фото», – дип, ризалашты. Ул фото әле дә саклана. Флюра апага «Әниемә» җырын күп тапкыр уйнарга туры килде. Рәнҗеп китмә, Флюра апа. Минем өчен син уңай кеше идең.

«Флюра Сөләйманова – архив, аяклы тарих ул»

Татарстанның халык артисты Зөлфия Шакирова мәшһүр җырчыбызны «алтын фонд» дип атады.

– Татар, мөселман хатын-кызына хас булырга тиеш барлык күркәм сыйфатлар Флюра апада тупланган иде. Флюра апа – ятимнәрне үз баласыдай үстергән, кадерле әни, дәү әни булып яшәгән кеше. Эстрадага килгәндә, Флюра апа иң тыйнак җырчы иде. Ул олыгайган көненә кадәр зур исемнәр алмаса да, чын халык җырчысы булып танылды. Аны белмәгән кеше юк! Флюра апа – аяклы тарих, татар җырының архивы, алтын фонд ул, – диде Зөлфия Шакирова. – Флюра апа белән телефоннан сөйләшкәли идек. Ул бик ярдәмчел булды. Без бергә гастрольләргә йөрдек, аны үзебезнең концертларда да алып чыкканыбыз булды. Ул беркайчан да үзен өстен куймады, яшьләр янында – яшьләрчә, олылар янәшәсендә олыларча була белде. Ул – зур мәктәп, үрнәк.

«Мәшһүр дүртлекнең соңгысы иде»

Татарстанның халык артисты Искәндәр Биктаһиров Флюра Сөләйманованы югалту хәбәрен күңеленә бик якын алган. Остаз дип кенә түгел, гаилә әгъзасы дип тә телгә алды ул җырчыны.

– Флюра апа якын итә, ярата иде. Мөнәсәбәтләребез бик җылы булды, гомер буе шулай дәвам итте, – диде ул. – Әле бер айлап чамасы элек сөйләшкән идек. «Шалтыратуыңа рәхмәт, гел шалтыратып тор», – дигән иде. Башка артистлар миннән: «Флюра апаның хәле ничек икән?» – дип сорый. Соң, шалтыратыгыз! Бик матур итеп сөйләшә иде ул… Флюра апа бик мәгълүматлы кеше иде. Юкса музыка белгече дә, тәнкыйтьче дә түгел. Әмма бик күп нәрсәне белә иде. Төнлә шалтыратып: «Фәлән җырның куплетын белмим, авторын белмим», – дип сорасаң, мизгел эчендә әйтеп бирә иде бит, әй! Илһам абый шундый иде. Мәшһүр дүртлекнең соңгысы иде Флюра апа: Илһам ага Шакиров, Әлфия апа Авзалова, Габдулла ага Рәхимкулов һәм ул.

Татарстан дәүләт филармониясе архивыннан

Фикер

Ирлан ИСХАКОВ, Казахстанның Казандагы генераль консулы:
– Мин монда очраклы кеше түгел. Бу хәбәрне ишеткәч, килергә уйладым. Флера Сөләйманова Казахстан белән Татарстан арасында илче, дуслык күперен сузучы булды. Ул казах мәдәниятен Татарстанга алып кайтты. Флюра апаның «Әниемә» җырын бөтен кеше белә.

«Ул зур мирас калдырды»

Татарстанның халык артисты Гөлзада Сафиуллина:

– Флюра апабыз – безгә зур мирас калдырган җырчы. Беренчедән, иҗатчы буларак, моңлы җырчы буларак. Икенчедән, ул төрки дөньяны берләштерде. Аның «Әниемә» җырын бөтен төрки дөнья җырлый! Бөтенесе белә! Без Флюра апаны шул җыр аша белдек, таныдык. Аның шикелле тыйнак, уңган, кешелекле шәхесне табарга кирәк әле. Ул безгә үрнәк, юл күрсәтүче булды. Флюра апада хөсетлек хисе юк иде. Рухы шат булсын! – диде.

«Әллә түзем булды, әллә…»

«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең радиотапшырулар хезмәте башлыгы Тәүфыйк Сәгыйтов җырчының радиодагы эшчәнлеген искә алды.

– Аның китүенә әле дә күңел ышанмый. Без шактый еллар бергә эшләдек. Гаҗәеп әйбәт, киң күңелле кеше иде, – диде ул. – Флюра апа берәү белән дә сүзгә килмәде. Әллә түзем булды, әллә табигате шундый… Ярдәмчел иде, кешене тыңлый белде. Күп җырлары бездә иҗат ителде. Халык яратты, халык күтәрде, ул җырлар бөтен җирдән яңгырап торды. Бу җырларны инде хәзер Флюрасыз күз алдына да китереп булмый.

Флюра Сөләймановaның «ВТ»га биргән соңгы әңгәмәсеннән

«Матур тавышлы җырчылар бар, әмма буй җитмәслек дип әйтерлекләре юк. Кайсының тавышы бик көчле, әмма җылылыгы юк. Ул булмаса, тамашачыга якынаеп булмый. Минем дә әллә нәрсәм юк инде, нишләптер халык яратты».

«Эстрада каналларын карамыйм, алар бигрәк тозсыз. Әйтәм бит, җырчыларны берсеннән-берсен аерып булмый. Бертөрле кыяфәт, бертөрле тавыш. Элеккеге җырчыларны бер-берсе белән бутап булмый иде. Әйтик, Римма, Әлфия, Хәмдүнә, Илһам, Зөһрә – бутап буламыни аларны!»

«Тамашачы күтәреп диярдәй йөртте. Беренчеләр дә эшемне күрә белде. Анысында да түгел әле, җырларым халык күңелендә калды, менә шунысы хикмәт».

«Кадерләп үстергән җимешләре идек»

Флюра апа ятимнәрне үз канаты астына сыендырган ятим дә бит әле ул. Дус кызы вафатыннан соң, аның дүрт баласына әни булган кеше. «Әни берәү генә була ул», – дип, бу балаларны әлеге изге сүзгә кыстамый. Шуннан алар да, оныклары да аңа дәү әни дип дәшә башлаган. Дәү әнине югалту ачысын Булат, Алсу, Әлфия бергә күтәрә хәзер. Кадерле кешеләре турында иң матур сүзләрне яшь аралаш кына әйтә алды алар.

– Ул – ятимлектә үскән кеше, шуңа күрә безгә карата хәерхаһлы булды. Без үги ананың ни икәнен белмәдек, ул әни булды! Кайбер кешегә үз анасы да мондый наз, мәхәббәтне бирә алмый! Әти тормышында шундый кешегә юлыгып, бик бәхетле булды, без дә бәхетле идек, – диде кызы **Әлфия Асеева**. – Каты сөйләшмәде, ягымлы, йомшак булды. «Син болай эшләп дөрес итмәдең» дияр урынга, «И балам, болайрак итсәк, әйбәтрәк булыр иде, икенче юлы шулайрак итәрбез», – ди иде. Безнең хакка пенсиягә чыкты. Балаларны карарга вакыт кирәк, дия иде.

Сүзгә **Алсу** да кушыла:

– Җырдагыча, «кадерләп үстергән җимешләре» без аның…

…Җырчыны «Курган» зиратында җирләделәр. Флюра Сөләйманованың урыны оҗмахта булсын!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

СҮЗЕБЕЗ УРТАК БУЛСЫН

«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

Быелгы халыкара «Татар сүзе» телевизион нәфис сүз бәйгесендә мари, удмурт, чуаш, мордва халыклары вәкилләре дә катнаша алачак. Бу хакта чарага багышланган матбугат очрашуында сөйләделәр. Яңалыклар исә моның белән генә бетми…

Быел ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау комиссиясе гамәлгә куйган «Татар сүзе» халыкара нәфис сүз бәйгесе дүртенче мәртәбә уздырыла. Оештыручылар – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе һәм «Шаян ТВ» каналы.

– Узган елгы бәйгедә 3,5 мең кеше катнашты. Бик зур нәтиҗәләргә ирештек. Шул исәптән «Яңа Гасыр» һәм «Шаян ТВ» телеканалларында яңа кешеләр барлыкка килде. Быел исә катнашучылар саны тагын да күбрәк булыр дип уйлыйбыз. Бәйгедә «Туган тел» номинациясе барлыкка килде. Быел башка халык вәкилләре дә катнашыр дип өметләнәбез. Алар да үз сүзләрен җиткерергә тиеш, – диде оештыру комитеты рәисе, «Шаян ТВ» каналының башкарма директоры – баш мөхәррире Рамилә Сәхабетдинова.

Сүз уңаеннан, узган елгы «Татар сүзе»ндә Татарстан гына түгел, Мари Эл, Самара, Төмән, Ямал-Ненец округы, Белоруссия, Төркиядән дә катнашучылар бар иде. Бәйгенең гала-концертында Салехард шәһәреннән килгән Екатерина ханым Әхмәтҗанованың сәхнә гөрләтеп биюе әле дә истә.

Нинди яшь категорияләре һәм номинацияләр бар? Катнашучыларның эшләре түбәндәге яшь категорияләрендә бәяләнәчәк:

– 7 яшькә кадәр (7 яшьне дә кертеп);
– 8–13 яшь (8 һәм 13 яшьне дә кертеп);
– 14–17 яшь (14 һәм 17 яшьне дә кертеп);
– 18 яшь һәм өлкәнрәкләр;
– үзе язган әсәрләрне сөйләүчеләр – 15 яшь һәм аннан өлкәнрәк катнашучылар;
– иҗади гаилә;
– профессионаллар. Биредә атказанган, халык артистлары, шулай ук театр, кино, концерт оешмалары артистлары, дикторлар, нәфис сүз осталары, театраль уку йорты укытучылары һәм башкалар катнаша;

ПРЕМИЯ ФОНДЫ – 1,5 млн сум

7 яшькә кадәр:
I урын – 25 мең сум, II урын – 20 мең сум, III урын – 15 мең сум.

8–13 яшь:
I урын – 30 мең сум, II урын – 25 мең сум, III урын – 20 мең сум.

14–17 яшь:
I урын – 35 мең сум, II урын – 30 мең сум, III урын – 25 мең сум.

18 яшь һәм өлкәнрәк:
I урын – 50 мең сум, II урын – 45 мең сум, III урын – 35 мең сум.

Үзе язган әсәрләрне сөйләүчеләр – 15 яшь һәм аннан өлкәнрәк:
I урын – 50 мең сум, II урын – 40 мең сум, III урын – 35 мең сум.

Иҗади гаилә:
I урын – 80 мең сум, II урын – 70 мең сум, III урын – 50 мең сум.

Профессионаллар:
I урын – 80 мең сум, II урын – 70 мең сум, III урын – 50 мең сум.

«Туган тел» махсус номинациясе:
дүрт җиңүчегә дә – 30ар мең сум.

– «Туган тел» махсус номинациясе мари, удмурт, чуаш, мордва халыклары вәкилләре өчен. Яшь чикләве юк.

Номинацияләр: «Проза», «Поэзия», «Туган тел» махсус номинациясе (катнашучылар туган телләрендә төрле жанрдагы, шул исәптән үзләре язган әсәрләрне башкара ала).

Катнашыр өчен нәрсә эшләргә? Бәйгедә катнашыр өчен, гариза белән видеоязманы tatarsuze2024@yandex.ru электрон адресы буенча җибәрергә кирәк. Гаризалар 30 ноябрьгә кадәр кабул ителә.

P.S. Узган бәйгеләрдә, шәһәрдә үскән, төрле түгәрәкләрдә шөгыльләнгән, телевидение һәм башка чаралар аша танылган балаларны гап-гади авыл балалары белән бер калыпка салмаска кирәк, дигән кебек фикерләр ишетелде. Балалар арасында да «Профессионаллар» номинациясе өстәсәләр, гаделрәк булыр иде, диештеләр. Оештыручылар исә балаларны аермауларын, барысының да тигез булуын ассызыклады. «Бүген авылда да, шәһәрдә дә мөмкинлекләр бар. Сәләте бар икән, без ул баланы күрәбез, тиешенчә бәялибез», – диде бу җәһәттән оештыру комитеты әгъзасы Роза Әдиятуллина.

Фикер

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, бәйгенең жюри рәисе:
– «Татар сүзе» башка бәйгеләрдән аерылып тора. Аның максаты – халыкны сәнгатьле итеп укуга җәлеп итү генә түгел, гомумән, аның әдәбиятка, тел сәнгатенә карата кызыксынуын арттыру. Шул рәвешле без укучыларыбызны да арттырабыз дигән сүз. Бу җәһәттән әлеге бәйгенең әһәмияте бик зур.

Чын безнеңчә…

Милли кием

Тарих, зәвык, миллилек. Танылган модельер Ләйсән Хаҗиеваның «Милли стиль by Ләйсән Хаҗиева» дип исемләнгән яңа кием коллекциясен тәкъдим итү кичәсен кыскача әнә шулай сыйфатларга мөмкин. Ләкин тәкъдим ителгән һәр образ, һәр кием артында күпме хезмәт һәм эзләнүләр ятуын алай гына тасвирлап булмас.

Хәер, аларын автор үзе генә белә инде. Без – нәтиҗәгә карап сокланучылар гына. Ә милли стильгә, милли модага багышланган чара берәүне дә битараф калдырмагандыр. Ефәк, бәрхет, табигый мамыктан ясалган кием коллекцияләре берничә чорны колачлады. Әйтик, беренче булып подиумнан «Сөембикә» коллекциясе киемнәрен кигән туташлар үтте. Бу модельер Ләйсән Хаҗиеваның тәүге иҗат җимешләре икән. Төсләр, тукымалар, фасоннар – барысы да ханбикә яшәгән чорга алып кайтты кебек. Бу коллекциядә яшел, көрән, алтын төсләр һәм ефәк тукымалар, бала итәкле озын күлмәкләр өстенлек итте. Баш киемнәре, затлы камзуллар зәвык өстәде.

«Яз – җәй 2023–2024» коллекциясе исә шул чордагы табигатьне хәтерләтте. Төсләрнең һәм тукымаларның дөрес сайлануына бәйле инде бу. Әлеге коллекциядә миллилек мода дөньясындагы тенденцияләр белән үрелгән иде. Соңгы арада табигый төсләр чыннан да игътибар үзәгендә бит. Миллилеккә килгәндә, кызларның берсе дә калфак та, камзул да, хәтта изү дә кимәгән иде. Ләкин ниндидер кечкенә элементлар барыбер дә игътибарны җәлеп итеп торды. Ләйсән Хаҗиева сүзләре белән әйткәндә, милли кием ул калфак кына түгел бит.

– Минем өчен милли стиль ул – заманча тукымалар, заманча тенденцияләрне, татарларга хас булган бизәлеш белән тегү үзенчәлекләрен исәпкә алып тегелгән киемнәр. Мин үзем 69 төрле стиль беләм. Аларның барысына да милли үзенчәлекләр өстәп була. Ягъни калфак кию үзеңнең татар хатын-кызы булуыңны күрсәтүнең берләнбер ысулы түгел, – дип аңлатты модельер.

«Татар-информ» / Рамил Гали

Фикер

Ләйсән ХАҖИЕВА:
– Безнең милли кием юнәлешендә зур упкын бар. Бер гасыр элек татарлар милли киемнән йөргән. Әмма инкыйлаб чорында бу тыела. Хәзер без яңадан мода революциясе ясыйбыз. Безгә менә шушы 100 елны куып җитәргә кирәк. Һәм бу эш бик тиз арада башкарылырга тиеш.

Шуннан соң без быел Татарстанның иң яхшы товарлары арасында җиңү яулаган «Тукай кызлары» коллекциясе белән таныштык. XX гасыр башында туташ-ханымнар яратып кигән кечкенә генә калфаклар, ефәктән тегелгән, асылташлар белән бизәлгән күлмәкләр…

Соңгы коллекция исә җәйге-көзге чорга багышланды. Быел көзен модага туры китереп киенергә теләүчеләр колагына: шулай ук табигый, ачык төсләргә, табигый тукымаларга игътибар итегез. Әлеге коллекция дә нәкъ менә шуларга бай иде.

Шунысы да игътибарга лаек: яңа кием коллекцияләре тәкъдим итү гадәти генә форматта узмады. Подиумга модельләрдән тыш, Зөлфирә – Алмаз Мирзаяновлар, Алсу – Азат Фазлыевлар, Рината Тэй да чыкты. Мода күрсәтергә түгел, кичәне җырга-моңга төрергә, билгеле. Сүз уңаеннан, Ләйсән Хаҗиева иҗат иткән образларны күп кенә артистлар да куллана. Әйтик, Фазлыевлар гаиләсе коллекциясендә модельерның 13ләп иҗат җимеше бар икән. Милли стильне пропагандалауда артистлар тагын да активрак катнашса иде дә ул…

Лилия ГЫЙМАЗОВА

УКУЧЫ СҮЗЕ

Сеңлемнең туган көне

Уйларым еракта калган елларга алып кайта. Әнием 1959 һәм 1962 елларда игезәк кызлар таба: Халидә – Халисә, Резеда – Рәзинә. Ләкин безгә парлап үсәргә насыйп булмый. Беребезнең пары – 7 ай, икенчебезнеке 40 көн генә яшәп, дөньялыктан китәләр. Сүзем кечкенә сеңлем турында иде.

Алары алып кайтырга дип, әти Әтнә хастаханәсенә абыйны, апаны, мине алып бара. Ләкин Рәзинәбез дә кыска гомерле була. Сеңлем Резедага 9 ай булганда, әтиебез фаҗигале төстә үлеп китте. «Әти» дип бер тапкыр да әйтә алмыйча үсте ул. Кечкенәдән уйчан, сабыр, тыйнак булды. Без – олырак балалар мәктәптә, ул өйдә ялгызы калган вакытлары да күп булды. Күрше малае Рамил белән дуслар, бергә уйныйлар иде. Кайвакытта әниемнең туган авылы Субаш Атыда әбиемдә тора иде ул. Әбием догалар да өйрәтә. Резеда аларны яттан өйрәнә, ләкин кешегә сөйләми, ояла. Бервакыт шулай каравыт астында каз утыра икән. Сеңлем аягын салындырып утыра да, ана каз тешләп алган. Шунда: «Бисмилләһи-р-рахмәни-р-рахим», – дип сикереп торган.

Субаш Атыдан бик матур кыз бала булып, чәчләрен озын итеп үстереп кайтканын хәтерлибез әле. Күршебез мәктәптә бик яхшы билгеләренә генә укыды. Математиканы бик яхшы белә, рәсемне бик матур ясый, әзләреп баянда уйный иде. Мәктәпне тәмамлагач, ул да минем янга педучилищега укырга килде. Мин – 4 нче курста. Бер бүлмәдә тордык, икебез бер караватта кочаклашып йокладык. Абый-апаларым дип яратып, хөрмәтләп яшәде. Мин киткәч, әни янында калды, бер мәктәптә эшләделәр.

Аннары язмыш юллары аны Арчага алып килде. Үзе укыган училищеда укытучы булып эшләде. Бик сагынып, яратып искә алалар хезмәттәшләре дә, укыткан укучылары да.

Казыксыз җиргә казык кагып, яңа өй җиткерделәр. «Апай, монда күчкәч, сулышларым иркенәеп китте», – дия иде. Бик яратып ике малай үстерде. Игелекләрен генә күрә алмады. Ризыкларны тәмле итеп әзерли иде. Кунакларны хөрмәт итә иде. Иде, иде, иде... Бик авыр бу юлларны язу. Тормышны яратып яшәде, тырышып эшләде. Әле яшәргә дә яшәргә иде. Нишлисең, Раббым гомерләрен кыска итеп яраткан. Язган истәлекләрем сеңлем Резедага дога булып ирешсен. Авыр туфрагы җиңел, рухы шат булсын.

Халидә ВАФИНА.
Арча, Чиканас

Көзбикә

Көзбикәнең эше тыгыз вакыт,
Кулларында – буяу, пумала.
Ул өлгерде инде яфракларны
Алтын, бакыр төскә манарга.

Миләшләргә, утлы баланнарга
Тагып чыкты кызыл алкалар.
Яннарыннан узып барганнарны
Кызыктырып үзенә тарталар.

Җил исүгә, вальс уйнап йөри
Сары, кызыл, коңгырт яфраклар.
Көзнең көе бермәл туктап китсә,
Аяк асларына яталар.

Ә мин кыймыйм аяк басарга да
Рәссам чиккән көзге келәмгә.
Сихерләнеп: «Яз бу матурлыкны!» –
Диеп дәшәм серле кәләмгә.

Халидә ХӘМБӘЛ

Илдар Мөхәммәтҗанов

КОЙМА ДА ТОТА, УТЫН ДА ЯРА

Җитмешенче – туксанынчы еллар. Зәй районындагы Федоровка мәктәбенең (хәзер ул юк инде) гөрләп торган мәле. Монда дистәгә якын авылдан укучылар йөреп укый. Мәктәп биләмәсендә интернат, ашханә, остаханәләр тезелгән. Кышын 28 мич ягыла, интернатта 150 укучы яши. Үзе бер зур хуҗалык, диләнке алып, утын кисеп, ярып өю укучылар карамагында. Биләмәне карап, тәртиптә тотуга да алар җаваплы.

Шул рәвешле без интернатта яшәп, тәҗрибә участогында эшләп, хезмәтне яратып үстек. Булдыра алуыбызга сөенеп, җәмгыятькә файдалы икәнлегебезне тоеп яшәдек. Безне «Мичурин»лыкка Зәйдә генә түгел, Татарстанга атаклы бакча үстереп танылган биолог Хәнифә апа Миңнегулова әзерләде. Эшкә өйрәтеп, үзең карап, тәрбияләп үстергәннең кадерен белергә дә өйрәтте ул. Ә бит җәен шул тәҗрибә участогына практика узарга җиде чакрым җәяү төшә идек. Хәнифә апа үзе дә күрше Апач авылыннан җәяү йөреп укыта. Биология укытучысы буларак, ул һәр үсемлек, һәр бөҗәккә серле бер дөнья итеп карарга өйрәтә, экскурсияләргә еш алып чыга иде. Тырышлыгы бушка китмәде: мәктәп яны тәҗрибә участогында мул итеп җиләкҗимеш, яшелчә үстерде. Һинд бәрәңгесенә кадәр үсә иде. Бер елны мәктәбебез җиләк-җимеш һәм яшелчә белән Казанда республика буенча мәктәпләр арасында оештырылган күргәзмәдә катнашты. Әлеге эшлекле сәфәрдән соң Федоровкада мәктәп эшчәнлеге буенча биология укытучылары өчен районкүләм семинар оештырылды, мәктәп директорлары киңәшмәләре, чыгарылыш класс укучыларының семинарлары узды. Район Советының чираттагы күчмә утырышының бирегә оештырылуы да хәтеремдә. Шул рәвешле мәктәп республикада мәгълүм уку йортына әйләнде.

Хәнифә апаның тырыш, намуслы хезмәте тиешенчә бәяләнде.

– Зәйдә беренчеләрдән булып «укытучы-методист» исеменә лаек булдым, – ди ул.

СССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә «Халыклар дуслыгы» ордены белән дә бүләкләнә. Укытучыбыз «РСФСРның атказанган укытучысы» мактаулы исемен лаеклы йөртә.

Сигезенче дистәсе тулган Хәнифә апа әти-әнисе нигезен саклап, авылдашлары, хезмәттәшләре, укучылары хөрмәтен, игътибарын тоеп яши.

– Хәнифә апам бөтен хуҗалык эшен белә: кирәк икән, койма да тота, электр чыбыкларын да суза, утынын да кисә, яра. Чын мәгънәсендә универсаль зат, – ди абыйсы Хатыйп Миңнегулов аның турында.

Шагыйрь дә ул. Күңелендә булганнарын, уй-кичерешләрен шигъри юлларга сала. Ике кисәктән торган «Әнкәй йөрәге икән» исемле китабы бар.

Хәнифә апаның укучылары кайсы тармакта гына хезмәт куймый! Алар арасында укытучылар, биологлар, табиблар шактый. Татарстанның атказанган табибы Григорий Абрамов медицина хезмәткәрләренең «Ак чәчәкләр» бәйгесендә үзен лаеклы һөнәр иясе дип танытты. Аның укучыларында хезмәтне ярату, тырышлык, кешелеклелек сыйфатлары яши.

Рәзимә КАШАПОВА

РУХИ БҮЛӘК

Сиксән сигез яшьлек композитор, Татарстанның халык артисты Әнвәр Шәрәфиев шушы көннәрдә халкына рухи бүләк ясады: Татарстан китап нәшриятында аның «Моң чишмәсе» исемле китабы 1000 данә тираж белән басылып чыкты.

Китапка кереш сүзне Россия һәм Татарстан Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин язган. «Уйнагыз, гармуннар!» җырын ишетмәгән кеше бик сирәктер. Бу җыр 1986 елдан башлап Казанда һәр ел саен уздырыла торган республикакүләм гармунчылар фестиваленең дә исеме булып тора, һәм ул Әнвәр Шәрәфиевкә республикада гына түгел, Россиядә, хәтта чит илләрдә дә танылу китерде», – дигән ул.

Китапның музыкаль мөхәррире – күренекле композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Риф Гатауллин. Аның җыентыкка кертелгән язмасы исеме китап исеме дә булып тора. 200 биттән арткан әлеге нотальы басмада

балалар һәм хор өчен җырлар, камера һәм симфоник музыка, композиторның тормышы һәм иҗаты турында төрле елларда матбугат битләрендә дөнья күргән мәкаләләр, фоторәсемнәр тупланып бирелгән.

«Миңа бәхетле картлык насыйп булды», – ди Әнвәр ага, шатлыгы белән уртаклашып. Сүз уңаеннан, композиторның туган авылы Урсай быел үзенең 325 еллык юбилеен билгеләп үтте.

Республикабызда игълан ителгән «2023 ел – Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы» программасы кысасында 15 сентябрьдә башкалабыз Казанның Ленин исемендәге мәдәният сараенда Азнакай районы «Чатыртау кунак җыя» бәйрәме үткәрде. Әнвәр ага Шәрәфиевнең әле генә «табадан төшкән» өр-яңа китабы якташлары күңеленә хуш килде һәм бәйрәм әнтәлеген тагын да баетты.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ

ШӘМӘРДӘННЕҢ ШӘМДӘЙ ЕГЕТЕ

«Татар-информ»

Нәкъ Казан уртасындагы Ратуша бинасында Татарстанның атказанган һәм халык рәссамы, тумышы белән Саба районының Шәмәрдән эшчеләр бистәсе егете Мөдәррис Миңһаҗевка 70 яшь тулу уңаеннан күргәзмә эшли. Яшьтәшем Мөдәррис – Татарстанга, татар иленә, тарихына, мәдәниятенә саллы өлеш керткән шәхес.

«Әни» дип абына-сөртенә сөенеп йөгерер мәлдә, 3 яшендә ул дөньядагы иң якын, иң газиз кешесен югалта... Үги ана хакында авыр сүзләр ишетергә гадәтләнгәнбез. Ә менә алмадай тумрап торган Мөдәррискә һәм аның апа, эне-сеңелләренә әниләрен алыштыра әлеге оҗмах рәхәтлекләренә генә лаеклы, мәрхәмәтле җан.

Рәссамны Казанга, Рәссамнар берлегенең беренче урынбасары вазыйфасына чакырып китерүләренә дә җиде ел тулды. Бу елларда зур үзгәрешләр булды. Бер-бер артлы грантлар оталар – Россия буенча мәртәбәле күргәзмәләр оештырыла башлады. Бөтен ил күләмендә Татарстаныбызда симпозиумнар оештыручы да ул. Мөдәррис идарәгә килгәч, Рәссамнар оешмасы шык үзгәреп, җанланып китте.

Ә бит нәкъ 27 ел элек ул Шөгер төбәгенә килеп, анда да рәссамнар эшчәнлегенә җан өргән иде. Лениногорскига килеп, яктылыкны каплап торган нурсыз пәрдәләрне ачып җибәргәндәй – сәнгатебез, мәдәниятебез җанланып-терелеп китте, күңелләребез үсеп киткән кебек булды шул вакытларда. Шәһәрдә аны белмәгән, кайнар кулын кысмаган кеше бик сирәктер дә әле ул. Бик тиз аралашучан, кызыклы әңгәмәдәш, тирә-юньдәгеләргә бары тик ихлас елмаю гына бүләк итүче, теләсә нинди табынны мавыктыргыч итеп алып бара белүче гаҗәеп табынчы ул!

Әйткәнемчә, Мөдәррис – киң колачлы иҗатчы. Портрет, натюрморт, пейзажларны да бер үк дәрәҗәдә кабатланмас, оста итеп ясый сәнгать әһеле. Шәһәребезнең Мәдәният сараенда урнашкан милли китапханәдәге, мәктәпләрдәге туган ягыбыз язучыларының портретлары үзе генә дә ни тора!

Рәссам Мөдәррисне өйдә туры китерәм димә, ул юлда, сәфәрдә – симпозиумнарда. Аның шәхси күргәзмәләре республикабыздан тыш, Кырымда, Ижау, Октябрьский, Уфа, Мәскәү, Санкт-Петербург, Самара, Чабаксар калаларында да кызыксыну уятты, киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде. Ә инде портрет остасы сыйфатында иҗат иткән әсәрләре аеруча игътибарга лаек.

Республикабызның күренекле җитәкчеләре, галимнәре, язучылары, аерым алганда, өч бертуган Миңнехановлар, аларның әти-әниләре, Индус һәм Энгель Таһировлар, Азат Әхмәдуллин, Әбрар Кәримуллин, Шәүкәт Биктимеров, Разил Вәлиев фотопортретлары аеруча уңышлы дип санала.

Мөдәррис дустым белән телефоннан еш аралашабыз. Тавышын ишетүгә, кимендә бер ел күрмәгәндәй шатлана, сөенә, иҗат җимешеңне бирелеп тыңлый, үзе әйткәндәй, язганнарыңны күз алдына картина рәвешендә бастырырга тырыша, ә инде җаныңа бик хуш килсә, «тәннәрем чымырдап китте» дия.

Тыңгысыз, олы йөрәкле, киң колачлы рәссам Мөдәррис Миңһаҗев 70 яшен рәсем сәнгате мәйданында каршылый. Егетлек яшь белән түгел, ә илгә, милләтеңә, халкыңа күрсәткән игелекле эш-гамәлләр белән билгеләнә.

Таһир ШӘМСУАРОВ

Авылча яшәп ятыш

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Бу рубрика сезнең күңелләргә бигрәк тә хуш килер, мөгаен. Сез ниләр майтарып ятасыз? Нинди яңалыклар бар? Языгыз әле безгә. Башкалар белән дә уртаклашыйк.

Фирдүсебез ялга кайтты

Арча. Ташкичү

Туганнарын, дусларын, авыл халкын сөендереп, Фирдүсебез тагын чираттагы ялга кайтты. Бу юлы күкрәгенә медаль тагып, горур атлап, сөенеп, ашкынып кайтты. Аны каршы алырга әнисе, туганнары, күршеләре һәм дуслары җыелдык. Барыбыз да куанычлы күз яшьләребезне тыя алмадык. Их, сугышлар бетеп, барлык егетләребез исән-имин кайтсыннар иде, инде безнең арадан киткәннәрнең урыннары оҗмах түрләрендә булсын, якыннарына Аллаһ сабырлык бирсен.

Эш урыным – гөлбакча

Озакламый ягу сезоны башлана, шунлыктан безнең мәдәният йортыбызда да, елдагыча, әзерлек эшләре бара. Торган җирең, эш урының һәм күңелең чиста булганда гына яшәү матур, эшләү рәхәттер ул. Аның өчен гел хәрәкәттә булу кирәк, барысы да үзебездән тора. Илләребез тыныч, күкләребез аяз булсын.

Беренче ярдәм күрсәтү

Зәй. Сармашбаш

Урамда сөяләп утырган, егылган кешеләрне күргәч, гадәттә, исерек инде бу, дип уйларга күнеккәнбез. Югыйсә бу кешенең ярдәмгә мохтаҗ булуы да бар. Баксаң, авыр хәлдә калган кешегә ярдәм итә алып та, битараф узып киткән өчен җинаять җаваплылыгы каралган икән.

Ничек кенә булмасын, ярдәм итү – беренче чиратта кешелеклелек билгесе. «Ә авыр хәлдәге кешегә файда китерү өчен, аз булса да беренче медицина ярдәме күрсәтү кагыйдәләрен белергә кирәк», – ди авылыбыз фельдшеры Гүзәл Мәрданова.

«Һәр күңелдә шигырь уты бар»

Буа. Иске Суыксу

Шулай дип исемләнгән шигъри кичәбезне Иске Суыксу авылы килене Шәрәфуллина Мөршидә апага багышладык. Ул 40 ел балаларга белем бирә. Ә укытучы булу ул һөнәр генә дә түгел бит әле, ул – язмыш! Мәктәп елларыннан башлап шигырьләр иҗат итә ул. Алар газета-журналларда басылып чыга. Кичәдә аның туган ягы, яраткан эшен сагынып язган шигырьләрен тыңладык, фикер алыштык. Ахырдан тәмле итеп чәй эчтек.

Көзге байлык

Яшел Үзән. Мулла Иле

Мулла Иле мәдәният йортында «Оста куллар» берләшмәсе эшләп килә. Сәнгать җитәкчесе Гөлназ Гыйззәтуллина «Көзге пейзаж» темасына рәсем бәйгесе үткәрде. Көз ае – алтын чор. Балалар бәйгедә бик яратып катнаштылар. Һәрберсе матурлыкны күрә белде.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 14 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 53^5 статьяның 1 пунктында «һәм аларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 55 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының программаны раслаган норматив хокукый акты нигезендә» сүзләрен «дәүләт программаларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән исемлеге һәм структурасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «билгеләгән срокларда» сүзләрен «тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт программалары агымдагы финанс елының 1 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына туры китерелергә тиеш.»;

3) 55^1 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

4) 55^2 статьяның 2 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче һәм бишенче абзацлар өстәргә:

«авыр йөк транспорт чаралары тарафыннан региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына китерелә торган зыянны каплау исәбенә түләүдән Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;

авыр йөк һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлардан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;»;

б) дүртенче – алтынчы абзацларны тиешенчә алтынчы – сигезенче абзацлар дип санарга;

5) 9^2 кушымтаның 8 пунктында «чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы законы» сүзләрен «чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы законы» сүзләренә алмаштырырга;

6) $9^{2.1}$ кушымтаның 6 пунктында «чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы законы» сүзләрен «чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы законы» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2022 елның 26 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда «$31^{1.2}$ статьясындагы 3 пунктының,» сүзләреннән соң «32 статьясындагы 3 пунктының (чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы дәүләт эчке хисаплашулары программасы өлешендә),» сүзләрен өстәргә, «43 статьясындагы бишенче абзацының (федераль законнарда билгеләнгән очракларда)» сүзләреннән соң «, 53^1 статьясының, 61 статьясындагы 1 пунктының» сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. 2023 елда Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына 2023 елның 30 октябреннән дә соңга калмыйча 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын кертә дип билгеләргә.».

3 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55^2 статьясындагы 2 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килүче хокук мөнәсәбәтләренә 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеттан башлап кагыла.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 14 сентябрь
№ 75-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык алтынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык алтынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турында еллык юлламасы.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2099-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык җиденче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык җиденче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфасына Вәлиев Альберт Шәүкәт улын билгеләп кую турында.
3. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле турында.
4. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 459-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 456-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 471-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 472-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 473-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» 475-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
10. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 476-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 468-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
12. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 469-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
13. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» 454-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 462-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 467-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
16. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 442-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
17. «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 15 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 464-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
18. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 458-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
19. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 460-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
20. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 465-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
21. «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 457-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
22. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 470-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
23. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 466-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
24. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 461-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
25. Югары белем бирү мәгариф оешмаларының спорт-савыктыру лагерьларын реконструкцияләү турында Россия Федерациясе фән һәм югары белем министры В.Н. Фальковка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында.
26. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның сентябренә кадәр чордагы эше турында хисабы.
27. 2022 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады.
28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.45 статьясына үзгәреш кертү хакында» 406657-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт сере булган белешмәләрне үз эченә алган мәгълүматны саклау өлкәсендә административ хокук бозулар хакында эшләрне карау вәкаләтләрен төгәлләштерү турында).
29. «Россия Федерациясе Урман кодексына үзгәрешләр кертү турында» 401706-8 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт бюджет учреждениеләренең һәм автоном учреждениеләренең икътисадый тотрыклылыгы механизмын булдыру өлешендә).
30. Хөкүмәт сәгате: «Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы хакында».
31. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2104-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп өч елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов суд районы буенча:

1 нче суд участогына – Баязитов Арслан Рамил улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Мәскәү суд районы буенча:

1 нче суд участогына – Баһавиева Гүзәл Идуат кызын;

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:

15 нче суд участогына – Яхин Марс Сирень улын;

23 нче суд участогына – Җамалиев Эдуард Нуретдин улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Идел буе суд районы буенча:

4 нче суд участогына – Төхвәтуллина Лилия Иршат кызын.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп вәкаләтләре чоры чикләнмәгән вакытка түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров суд районы буенча:

1 нче суд участогына – Шараев Айдар Ансар улын;

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:

2 нче суд участогына – Диярова Ләйсән Габденур кызын.

3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының вәкаләтләр чоры алдагы вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән башлана.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2105-VI ДС

Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфасына Вәлиев Альберт Шәүкәт улын билгеләп кую турында

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Вәлиев Альберт Шәүкәт улын Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфасына 2023 елның 26 октябреннән билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2106-VI ДС

Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле турында

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

2023 елның 26 сентябреннән Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле итеп Никитин Сергей Геннадиевичны билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2107-VI ДС

Рәсми хәбәр

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Булдырь авыл җирлегендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:42:200501) 30.06.2023 № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Йолдыз бистәсе, Үзәк урам, 1а й. (телефон: +7(84342) 3-43-55, 4-64-79), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы хакимиятенең (https:// https://chistopol.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 10 октябрендә (11 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Йолдыз бистәсе, Үзәк урам, 1а й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 19 сентябреннән 2023 елның 10 октябренә кадәр һәм 2023 елның 10 октябреннән 2023 елның 13 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Кубас авыл җирлегендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:42:070401) 30.06.2023 № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Кубас авылы, Үзәк урам, 5 й. (телефон: (84342) 3-15-18, 3-15-78), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы хакимиятенең (https:// https://chistopol.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 10 октябрендә (09 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Кубас авылы, Үзәк урам, 5 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 19 сентябреннән 2023 елның 10 октябренә кадәр һәм 2023 елның 10 октябреннән 2023 елның 13 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Октябрь авыл җирлегендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:15:150301) 30.06.2023 № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Октябрь бистәсе, Үзәк урам, 7 й. (телефон: 8-843-79 31-4-27), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы хакимиятенең (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 10 октябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Октябрь бистәсе, Үзәк урам, 7 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 19 сентябреннән 2023 елның 10 октябренә кадәр һәм 2023 елның 10 октябреннән 2023 елның 13 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Чернышевка авыл җирлегендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:16:321101) 30.06.2023 № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка авылы, Клуб урамы, 1 й. (телефон: +7 (84365) 73-5-05), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең https://vysokaya-gora.tatarstan.ru;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 10 октябрендә (14 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка авылы, Клуб урамы, 1 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 19 сентябреннән 2023 елның 10 октябренә кадәр һәм 2023 елның 10 октябреннән 2023 елның 13 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Мач әйткән!

Генри ФОРД, автомобиль җитештерүче:

– Бөтен дөнья сиңа каршы булганда, шуны истә тот: очкыч җилгә каршы күтәрелә!

«Үпкәсез туй»

САЛАВАТ. ӘММА НЮАНС БАР

Салават Миңнехановны беләсез. Гүзәлем белән дә аерым таныштырасы юк. Зур сәхнәгә әле беренче генә адымнарын атлаган вакытта егетнең исем-фамилиясенә нык игътибар иттеләр. Үзе Салават, үзе Миңнеханов – мондый атың булганда уңышка ирешми мөмкинме соң? Йолдызлы гаиләне бүген зур сәхнәдә дә, туй-юбилейларда да очратырга мөмкин. Салават «Ха-ха-ханә»гә кызыклы хатирәсен сөйләде. Эстрадада әле эшли генә башлаган чорда аны бер юбилейга чакыралар. Бик теләп бара. Бәйрәмне башыннан ахырына кадәр шушы эштә махсуслашкан эвент-агентлык оештыра. Салават бәйрәм буласы җиргә килә, бик затлы җир, кунаклар да бик саллы. Өстәл янында олы яшьтәге әбиләр дә шактый, юбилярның туган-тумачаларыдыр инде. Ә чыгыш ясарга Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова кебек дәрәҗәле җырчылар килгән. Салаватның репертуары ул чакта аеруча хисси һәм дәртле иде. Җырчы яшьләрчә бер җыр «бәрә». Моңарчы җитди генә утырган әбиләр селкенгәли башлыйлар. Шулай итеп, җырчы бөтен залны кузгата. Соңыннан Салават Миңнеханов янына шушы бәйрәмне оештырган агентлык кешесе килә дә рәхмәтләрен әйтә. Сөйләшә торгач, шунысы аңлашыла: агентлык Салават Фәтхетдиновны чакырырга тиеш булган икән, әмма, бутап, Миңнехановны чакырган. «Но вы им тоже понравились», – дигән ахырдан оештыручы кыз. Менә шундый кызыклы хатирә. Бу хәлне Салават Фәтхетдиновка сөйли күрмәгез. Ни дисәң дә, ул бу көнне заказсыз калган бит.

Әз-мәз мәзәк

Бер фатирыбызда кеше тота идек. Сатарга булдык. Фатирның яңа хуҗалары анда яшәүчеләрне калырга күндергән. Үземне хәзер җир белән бергә крестьяннарны сатып җибәргән алпавыт сыман хис итәм.

* * *

Иртәрәк торсагыз, талашырга вакыт күбрәк калачак.

* * *

Психологта консультация узганнан соң Лилия ирен гаиләсенә кайтара алды. Балачакта үскән гаиләсенә.

* * *

Кешегә балык бирсәң, ул бер көн тук булыр. Кармак бирсәң – блесна, воблер алыр, көймә һәм моторга акчасын әрәм итәр, иске «Нива» һәм гаражлы булыр һәм «сентябрь салкын килде, кызылканат начар чиертә» дип мыгырданып йөрер.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Биштомлыктан

ИСКӘНДӘР МАҖАРАЛАРЫ

ЯТЫП ЯТА

Улым Искәндәр кичен минем урынга яткан да йоклаганга салышкан. Белеп торам: миннән бер әкият сөйләтмәкче.

Мин ачуланган булып:

– Нишләп ятасың монда? – дим.

– Ятып ятам, – ди Искәндәр.

Әйе, грамматика кагыйдәләре буенча, ул дөрес җавап бирә. Әкият сөйләми булмас...

АТЫЙ ТОРГАН АТ

Авылга китәр алдыннан Искәндәрдән сорыйм:

– Сиңа авылдан нәрсә алып кайтыйм, улым?

– Ат алып кайт.

– Ат бик зур бит ул, аны поездга кертмәсләр.

– Юк, андый ат түгел, атый торган ат.

Искәндәр кулына кашык тотып ашап күрсәтә. «Ашый торган аш» диюе икән. Бер-ике көн элек кенә мин аңа: «Авыл малайлары аш күп ашый, беләкләре шуңа күрә таза була», – дигән идем.

АЯКНЫҢ САБЫ

Искәндәр, елап, минем янга килде.

– Нәрсә булды? – дим.

– Ау-ырт-ты-ы-ы-ы... – Үзе балтырын тоткан.

– Кай җирең, аягыңмы?

– Ю-у-у-ук. Аякның сабы-ы-ы...

Тел гыйлеме буенча ул бу юлы да хаклы иде. Балтаның сабы бар, көрәкнең дә... Ул аларны белә иде. Ә нигә әле аякның сабы булмаска тиеш?

КӘФИТ

Улым белән аерылышам. Ике көнгә. Ул озата килә.

– Агайне (Искәндәр үзенә шулай зурлап дәшкәнне ярата), сиңа нәрсәләр алып кайтыйм?

Малай чүт кенә уйлап куйды да:

– Кәфит, – диде.

Ләкин минем: «Кәнфит күп ашасаң, егет булмыйсың, беләгең юанланмый», – дигәнне хәтерли, шуңа күрә тиз генә:

– Тәй этәргә, – дип өсти. Чөнки ул белә: чәй эчкәндә бер кәнфит рөхсәт ителә.

КУРКАК ШИКӘР

Өстәл тирәсендә чәй эчәргә җыелабыз.

Улым Искәндәр инде әллә кайчан килеп утырган, нәрсәгәдер ыгы-зыгы килә.

Аны капкачлы савыттагы шикәр кызыксындыра икән. Чәй хәстәрләү озаккарак киткәнгәдерме, аның сабырлыгы бетте – ул шикәр савытын ачып куйды.



– Нигә ачтың? – дим Искәндәргә.

– Шикәргә якты булсын, караңгыда курка ул... – ди.

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ

Исәнме, көз!

Сау бул, җәй!

vk.com

Олы яшьтә, җәй әрәмгә узды, дип уфтанмыйсың. Чөнки әрәмгә узган башка нәрсәләр дә бик күп.

◆◆◆

Көннәрдән бер көнне син өеңнән шорты белән чыкмый башлыйсың. Һәм бу 9–10 ай дәвам итә.

◆◆◆

Әллә ничә ташкабак кистем, берсендә дә икра юк!

◆◆◆

Дачаларыннан яңа көч туплап кайткан пенсионерлар көз көне хастаханәләрне штурмлый башлый.

◆◆◆

Балконга трусиктан чыгарга салкын була башлады, шуңа күрә башыма киям.

◆◆◆

Шкафтан җылы киемеңне алганда кесәсендә яздан онытып калдырган 100 сум булыр дип өметләнәсең, ә анда бары тик яздан калган тишек кенә була.

◆◆◆

Эссегә зарланудан туктап, салкынга зарлана башлый торган чор көз дип атала.

ӘХ, СЕЗ, МАТУР КЫЗЛАР!

– Кичә матайда барганда миңа сигнал биргән идең. Бәлки, танышырбыз?

– Мин сиңа, юлдан кит, дип пипелдәдем.

❤❤❤

Менә, әйтик, сиңа мондый сайлау тәкъдим иттеләр ди: кияүгә чыгасың яки иптәш кызың белән диңгезгә барасың – кайсы илгә барыр идең?

❤❤❤

– Моннан соң син өйләнергә тиеш.

– Мин инде өйләнгән.

❤❤❤

Башка кызлар үзләрен ташларлар һәм онытырлар дип курка. Мин исә үземне табарлар һәм искә төшерерләр дип куркам.

❤❤❤

– Сәлам! Хәтерлисеңме мине?

– Ычкын моннан!

– Димәк, хәтерлисең.

❤❤❤

Сезнең арада берни килеп чыкмас кешеләр бу дөньяда шулхәтле күп, ә син һаман шуларның берсе белән генә мәш киләсең.

❤❤❤

– Синең нинди чәчәк яратканыңны белмәдем, шуңа күрә башка кыз таптым.



vk.com

❤❤❤

– Безгә тормышка җитдирәк карарга кирәк. Йорт төзергә, балаларны аякка бастырырга...

– Туктале, мин синең фотографияңә лайк кына куйдым бит.

❤❤❤

Егет әйтте – егет онытырсың дип уйлады.

❤❤❤

– Сезнең гаиләгез бик бай. Әмма сезнең кызыгызга өйләнергә теләвемнең сәбәбе ул түгел. Төп сәбәп – кызыгызга булган мәхәббәтем.

– Өч кызыбызның кайсына өйләнмәкче буласың?

– Ә кайсын бирәсез?



УНИКАЛЬ СҮЗ – «СӨЮ»

Татарда бары тик шигырьләрдә генә кулланыла торган сүзләр бар. Мәсәлән, «сөю» дигән сүз. Ул ике җырның берендә очрый. Ә көндәлек тормышта миллион елга бер яңгырарга мөмкин. Менә, әйтик, берәр егет берәр кызга көндәлек тормышта «мин сине сөям» дип әйтсә, тегесе куркып качачак бит, дөрес кеше түгелдер бу, дип. Бүген хәләл җефетегез эштән кайткач, күзләренә туп-туры карап «мин сине сөям» дип әйтеп карагыз әле. Реакциясе нинди булыр икән?

Уйлану

ТОРМЫШ АВЫР

Фатир алмакчы идем, әмма, ай саен 21 мең сум түли алмаячаксың, дип банк ипотека кредиты бирмәде. Шуңа күрә ай саен 25 мең сумга фатир яллап торырга мәҗбүрмен.

⌃⌃

– Бүген җитәкчемә әйттем: илдә уртача хезмәт хакы 15 процентка арткан!

– Нәрсә дип җавап бирде?

– Телевизор карамаска кушты.

⌃⌃

– Әти! Безнең фатирны басканнар!

– Чәйнекне алганнармы?

– Юк.

– Чәй куеп җибәр әле.

⌃⌃

Пандемия вакытында сатып алган бәдрәф кәгазьләренең соңгысын кулландым кичә. Кыйммәтле кәгазьләргә инвестиция белән шөгыльләнмим бүтән.

⌃⌃

Соңгы чыккан «Айфон»ны алырга җыелган озын чират пүчтәк ул. Минем әти өйгә телефон кертүне 10 ел көтте.

vk.com

⌃⌃

Мәктәптә 11 ел уку дәверендә безгә түләүләрне ничек башкару, ипотеканы санау, салым түләү турында берни өйрәтмәделәр. Аның каравы мин суган күзәнәгенең төзелешен беләм.

⌃⌃

Минем ике халәтем бар:

1) Борчылам.

2) Борчылмый йөрүем озакка китте дип, сәерсенеп борчыла башлыйм.

⌃⌃

Бөтен сәрхуш эчүдән туктый. Кайберләре хәтта бу дөньяда.

⌃⌃

Картлык көнендә теш дәвалауга акчаны мәктәпкә йөргәндә әни биргән акчалардан җыеп барасы калган.

⌃⌃

Телефоныгызга открыткалар ничек килеп тора, кесәгезгә акча шулкадәрле килеп торсын.

ЗӨЛФӘТ ХӘЙРУЛЛИННАН ДУСЛАРЧА ШАРЖЛАР



Рабит Батулла

Мирсәет Сөнгатуллин

Рафил Җәләлиев

Салават Фәтхетдинов

Рамил Шарапов

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 14047 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 329

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.

График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+